
Ләлә Гыймадиева

# ЧУФУТ-КАЛЕ малайлары



Казан
Татарстан китап нәшрияты
2005

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-4
Г 92

**Гыймадиева Лэлэ**

Г 92 Чуфут-кале малайлары: Повестьлар.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.— 80 б.

Бу китапка кертелгән ике повестьта бер-берсеннән ерак торган ике дәвер, ике төрле яшәү рәвеше сурәтләнә. Ике дөнья — ике төрле тормыш, әмма аларның һәркайсының геройларын бер фикер берләштерә: дөньяны танып белүнең чиге юк, һәм аңа бару юлында һәркем үз куллары белән теләсә нинди могҗиза тудыра ала. Тик ул могҗизаны һәр дәвер кешесе үзенчә аңлый, үзенчә кабул итә...

ISBN 5–298–04056–X

© Татарстан китап нәшрияты, 2005

# ЧУФУТ-КАЛЕ малайлары

*Мажаралы повесть*



Ялтага сәфәр чыгасыларын ишеткәч, Рамазан юлга җәй башыннан ук әзерләнергә тотынды. Иң әүвәл каникул башлану белән бушап калган язу өстәленә Кырым турындагы китаплар кайтарып аударды. Төннәр буе тарих, география дәреслекләрен актарды (болай да яратып укый ул аларны, тәмам җенләндең инде шулар белән, дип тирги әнисе), әллә никадәрле хикәятләрне, риваятьләрне кабат-кабат күңеленнән кичерде. Алушта, Гурзуф, Бакчасарай, Иске Кирмән, Чуфут-кале... Бу атамаларның һәркайсында әллә ниткән сер яшеренгән шикелле тоела, шушы кадәр ашкынып та бара алмый калса...

Казанны чыгып киткәннең өченче көнендә малайның йокысы качты. Моңа кадәр поездның бер уңайга теркелдәвеннән гел йокыга оеп барган иде. Башта ук купеларының өске катына менеп кунаклады да, әниләренең вакыт-вакыт чәй эчәргә дип дәшкәләп торгызуына гына уянды. Бүген менә әтисенең: «Кырым җиренә кереп барабыз»,— дигән сүзләре айнытып җибәрде. Тәрәзәгә күз төшергән иде — хәйран калды. Мондый гүзәл манзара үз якларында да бардыр ул үзе, тик бусы моңарчы китаплардан гына укып белгән әкияти җирләр бит! Иксез-чиксез җәйрәп яткан сулыклар янәшәсеннән үттеләр — анысын Сиваш култыгы дип аңлаттылар. Очы-кырые күренмәс кебек тоелган биек күпер аша узганда, поездлары менә-менә егылып төшәр кебек тоелды Рамазанга. Аннары — таулар. Симферополь каласына килеп җитеп, автобус белән Ялтага таба юл тотканда да гел калкулыклар булды. Борылмалы-сырылмалы тау юлларыннан барганда: «Казан шоферларын монда китерсәңме... йөз метр узганчы мәтәлеп төшәрләр иде»,— дип уйлап куйды малай.

Ялтага төн ярып килеп төштеләр. Арыткан иде, артык хискә бирелеп утырырга хәл калмады. Баскыч-баскыч тар урамнардан абына-сөртенә барып, ниһа-

ять, кунакханәнең бөркү бүлмәсенә килеп аугандa, таң атарга җыена иде бугай инде. Шулкадәр тәмләп, изрәп йокланган, хәтта төш күрергә дә өлгерми калды Рамазан.

Аннан соңгы көннәрдәге берсеннән-берсе мавыктыргыч сәфәрләр һәркайсы төсле төш булып хәтеренә сеңә барды аның. Асылмалы юлдан мәһабәт Ай-Петри тавына менүләр, озын баскычлардан кармалана-кармалана карлы-бозлы мәгарә эченә төшүләр, шөһрәтле Севастополь, Керчь калаларына булган онытылмас сәяхәтләр... Ул инде Казанда чакта ук Кырымдагы истәлекле урыннарны ятлап бетергән иде, «тагын тегендә генә барыйк... аннары монда гына...» дия-дия, әтиләренең теңкәсен корытып бетерде. Бер иртәне әнисе, ниһаять, кистереп:

— Булды, җитте, килгәч-килгәч, әзрәк диңгез һавасы сулап ятарга да ярыйдыр,— диде.

Әтисе әнисенең сүзенә каршы килми дә килми инде. Шундый инде ул, улы өчен түгел, үзе өчен дә аннан узып берни эшләми. «Әниең алай иткәнне яратмас», «әниең ни әйтер», «әниең белән киңәш» — бар белгәне шул. Ә әнисен ансат кына ризалату өчен, айһай күп кирәк! Малайның кәефе төште, шулай да киреләнеп маташуның файдасы юклыгын да яхшы белә иде. Ул көнне иртәдән кичкә кадәр диярлек судан чыкмадылар. Анысы да рәхәт булды үзе. Рамазан бик шәп йөзә. Әтисе белән узыша-узыша су керделәр, туйганчы дулкыннар белән шаярдылар. Әнисе: «Ерак китмәгез!» — дип, яр кырыена баскан килеш гел кычкыргалап торды. «Үрдәк бәбкәләрен тәрбияләп үстергән тавык кебек»,— дип көлде аннан әтисе, үзенә ишеттерми генә. Ник дисәң, әнисе йөзә белми, «тәки өйрәтмәдең» дип, туктаусыз әтисен битәрли тагын үзе... Аннары, караңгыга хәтле кечке шәһәр белән хозурланып, диңгез яры буйлап башкалар кебек эленке-салынкы йөренеп алдылар. Бер әйләнделәр, ике, өч... Монысы Рамазанга бөтенләй ошамады, никадәр әрәм вакыт, дип пошыргаланды ул.

Икенче, өченче тапкырында да шул хәл кабатланды. Исәпләп караган иде, кайтып китәрләренә санаулы гына көннәр калганлыгын белгәч, бөтенләй күңеле сүрелде малайның. Аның әле планында әкияти Бак-

часарай каласы, мәшһүр Чуфут-кале кыялары бар иде, алары шул хыял гына булып калыр микәнни?

— Әни,— диде малай беркөнне, бик озак уйланып йөргәннән соң, бөтен батырлыгын җыеп,— мин бит инде сабый бала түгел, быел тугызынчыга барам. Җибәрегез үземне генә! Экскурсияләр көн дә булып тора, ялгызым гына бармыйм ич...

Җөмләсен төгәлләп өлгермәде, әнисенең дәһшәтле хәрәкәтеннән сагаеп, туктап калды Рамазан. Бик ачуы килгәндә, очып килеп, селтәнеп җибәрергә дә күп сорамый ул. Малай куырылып килде.

— Син нәрсә?! — Әнисе һәр сүзгә басым ясый-ясый әйтте.— Син нәрсә?! Бездә әндри казнасы бар дип белдеңме?! Булган кадәресенә рәхмәт әйтә бел! Үзе генә бара, имеш! Синең ишеләрне генә ияртеп йөриселәре калган ди анда! Ваемсыз, оешмаган! Беренче тукталышта ук адашып калачаксың бит син! Тегеләрендә дә авызыңны ачып йөрдең, ничә тапкыр җитәкләп алып килде сине әтиең...

Хәзер инде аны тиз генә туктатырмын димә! «Син бозып бетердең» дип, әтисенә бәйләнәчәк хәзер. Җайлырак вакытны туры китереп, Рамазан мыштым гына урамга чыгып сызды.

«Ваемсыз, сансыз, ачык авыз...» Берәр нәрсә булса, шул сүзләре белән бәгырьне теләләр. Элегрәк ул кадәр үк авыр булмый иде шикелле, хәзер андый чакларда әллә кайларга китеп югаласы килә башлый. Өчдүрт ел элегрәк бугай, класслары белән көзге урманга экскурсиягә алып барганнар иде. Гербарий өчен яфраклар җыйдылар. Нәкъ менә аның каршысында гына керпе очрап торганга ул гаеплемени? Шуның белән уйнап утыра торгач, онытылып кителгән, иптәшләре әллә никадәрле юл алган. «А-у!» дип кычкыра-кычкыра, бөтен урман буйлап эзләп йөргәннәр. Әй, эләккән иде әнисеннән соңыннан... Ә берсендә ипигә дип, кибеткә киткән җиреннән өч сәгать йөреп кайтты. Әтисе милициягә, тагын әллә кайларга шылтыратып бетергән. Ә ул шунда күчмә цирк тирәсендә генә йөргән иде. Дөяне бөтенләй урам якка ук чыгарып бастырганнар, Рамазан ипигә дигән акчасына, шуңа атланып, цирк ихатасын ике кат әйләнде. Онытыла торган гадәте бар инде, анысы хак. Ләкин ул бит начар юлда

йөрми, ник шулкадәр дөнья җимереп тиргәргә?.. Әле быел язын археологлар Казан Кремле астын казый башлаганнар, дип ишеткәч, дәрестән соң шунда барган иде. Өр-яңа курткасын эт итеп кайтып керде. «Ник кеше баласы кебек түгел соң син?!» — дип елый-елый тиргәде әнисе. Рамазан: «Кеше баласы тәмәке тарта»,— дип әрепләшә башлаган иде, колга буйлы малайның арт санына берне кундырмасынмы әнисе! Әй гарьләнгән иде шунда, кубарылып кабат чыгып китмәкче иде, әтисе тотып калды. Анда да: «Син аны аяктан егасың бит инде!» — дип, әнисен яклады. Хәер, ул аның үз алдында гына шулай диде. Әнисе, йөрәк даруы эчәргә дип, йокы бүлмәсенә кереп киткәч, җәлләп, малаеның башыннан сыйпагандай итте дә, колагына гына: «Ярар инде, улым, хатын-кыз белән булашмыйк»,— дип пышылдады.

...Ул көнне Рамазан диңгез буена төшмәде. Иртәнге аштан соң: «Башым авырта»,— дигән булып, караватында бөгәрләнеп ятып калды. Ышанмадылар, билгеле. Алай да ялынып маташмадылар. «Холкыңны күрсәтәсеңме? Суынгач, килеп җитәрсең әле»,— диде әнисе, әтисен култыклап алып. Аннары, күзләрен хәйләкәр ялтыратып: «Түлке шуны бел: әбәтне бүген яр буендагы испан ресторанында ашыйбыз, мондагы әчегән кәбестә шулпасы туйдырды»,— дип өстәде. Әмма Рамазан бүген көнне барыбер үзе генә үткәрергә булды. Теләсәң, Ялтаның үзендә дә карарлык нәрсәләр бардыр әле.

Тегендә сугылып, монда кагылып байтак йөрде, тик мөкиббән китеп карарлык нәрсә тапмады. Әбәт җитәрәк, «Экскурсияләр» дип язылган будкага килеп төртелде. Күңелсез генә андагы исемлекне караштырды. «Чуфут-кале» дигәненә озаграк текәлеп торды. «Автобус 12 сәгатьтә китә, 18 сәгатьтә кайта» диелгән. Мизгел эчендә Рамазанның башында өр-яңа план өлгереп җитте. Әниләре аның барып кайтканын сизми дә калачак! Менә кесә төбендәге гривналары җитсә...

Гривналары җитми иде, кунакханәгә йөгереп кайтып, запаска калдырылган тиеннәрен җыеп алып килде. Суыткычтан колбаса кисеп алып, бутерброд ясап тыкты. Беткән баш беткән... Бу уйдан кире кайту юк

хәзер. Ә әнисе белсә... Монысы турында Рамазан хәзергә уйламаска тырышты.

...Автобус кузгалып китүгә, малай киң итеп сулыш алды, бөтен гәүдәсен чиксез рәхәтлек биләп алды. Ниһаять, ниһаять!..

Алар, мондагы тәртип буенча, борылмалы юллардан гел акрынлап тауга күтәрелә бардылар. Инде кыя башына менеп җитәбез, аның теге ягында тирән упкын буладыр, дип уйласаң, киресенчә, тигез, киң дала башланып китә. Бер якта нәкъ бездәге кебек яфраклы урман, икенчесендә коточкыч тирән упкын. Шул юлдан узганда, Рамазанның йөрәге «менә чыгам, менә чыгам» дип типте. Кайчак янәшәдә генә җете яшел куаклыклар, шау җимешкә күмелеп утыручы абрикос, шәфталу, чия агачлары утырып кала. Инде еракта галәмәт озын таш стена булып сузылып киткән мәһабәт Чуфут-кале кыялары да күренә башлады. Аның зур-зур караңгы уентыларына карагач, гүя биек таш бинаның ишек-тәрәзәләре чокыраеп торадыр кебек тоелды Рамазанга. Йөрәге, әллә нинди зур могҗиза көтеп, сулкылдап куйды.

Чуфут-каледа меңәрләгән мәгарә бар икән. Шаккаткыч! Кайчандыр кешеләр шунда — мәгарә эчендә — тоташ калалар төзеп яшәгәннәр, ә кыя өсләрендә дошманнардан саклану өчен ныгытмалар корганнар. Экскурсовод хатын мәгарә шәһәрләренең кайчан барлыкка килүе хакында төгәл мәгълүмат бирә алмады. Моны тарихчыларның төрлесе төрлечә аңлата икән. Берәүләр урта гасырларда дип ышандырырга тырышса, икенчеләре инде таш гасырында ук Чуфут-кале мәгарәләрендә кешеләр яшәгәнен раслаучы дәлилләр барлыгын әйтә. Төрле чорда төрле дингә табынган булулары да билгеле — «шәһәр»ләрдәге мәчетләрнең, чиркәүләрнең, башка рәвештәге гыйбадәтханәләрнең күп булуы шул хакта сөйли. Бирегә кем беренче булып килеп утырган — греклармы, караимнармы, әллә Кырым татарларымы — гид монысына да төгәл җавап бирә алмады. Шунысы гына мәгълүм икән: Таврика (Кырымның көньяк-көнбатыш өлеше бик әүвәл шулай дип аталган) борынгы заман һәм урта гасыр культураларының «очрашу» урыны булган: скиф, эллин, иудаизм, мөселман, әрмән...

Рамазан боларны тын да алмыйча тыңлады. Ничаклы ачылмаган серләр бар тарихта! Вакыт машинасына утырып, әүвәлгегә кайтып килергә иде менә! Мәгарә калаларында яшәп карарга иде!

Ниһаять, автобус биек таш капка каршысына килеп туктады. Ары бара алмый, калган юлны җәяү үтәчәкбез, диделәр. Биеклекне авыр кичерсәгез, монда калыгыз, шушы ераклыктан гына күзәтегез, дип кисәттеләр. Өстәвенә сөяп куйган кебек тоелган текә калкулыклардагы тар, җайсыз кәҗә сукмагыннан атлыйсы икән. Экскурсоводка күбрәк яшьрәкләр иярде. «Мәгарә шәһәрләрен махсус шулай үтәргә җайсыз итеп кыя эчләренә төзегәннәр»,— дип аңлатты ул. Туристлар да монда килергә әллә ни атлыгып тормый икән. Ә Рамазан өчен бу юл бигрәк дулкынландыргыч булды. Таш түшәлгән тар сукмактан атлаганда, әйләнәтирәдә үсеп утыручы мәтрүшкәләр, кузгалаклар, тау чәчәкләре туган җирен хәтерләткән кебек булса да, башын күтәреп карагач, кул сузымы хәтле генә ераклыктагы галәмәт биек таш кыяның үзләре каршысына килеп баскандай булуы сискәндереп җибәрде. Шактый озак бардылар. Килеп җитү белән һәммәсе дә иң әүвәл ерактан чокыраеп күренеп торган теге уентылардан кереп-чыгып карады. «Ерак китмәгез,— дип кисәтте экскурсовод,— җир асты юллары мәкерле, адашканыгызны сизми дә калырсыз». Рамазан башта, кызыксынуын тыярга тырышып, шул ишек-тәрәзәләр тирәсендә генә йөрергә булды, аннары онытылып китте, бер «ишек»тән керде дә, мәгарәнең эченә үк узды, андагы өстәл-урындыкка охшаган шома ташлар өстенә утырып-утырып карады. Ниндидер эчке бер көч: «Менә монда гына, монда гына...» — дип, аны һаман алга таба әйдәкләгән кебек булды.Тау куышындагы лабиринт юл буйлап тагын бер-ике адым атлаган иде, мәгарә эче бөтенләй караңгыланып китте. Ул арада тышкы яктан шаулашкан, аның исемен атап кычкырган тавышлар ишетелә башлады. Моңа кадәр дә юлдашлары аны шулай дәшеп-дәшеп алгалаган иде инде. Рамазан айнып киткәндәй булды, каушый төшеп, килгән юлына кире борылды, кармалана-кармалана сыек кына яктылык төшкән якка таба атлады. Тик ни гаҗәп, теге тавышлар торган саен ераклаша

барды. Баксаң, бу яктылык һич тә ул кергән тау куышы ягыннан түгел, кыя өстен тишеп төшкән «кое» авызыннан сирпелә икән! Якынрак килеп, башын күтәреп караган иде, егылып китә язды: «кое» авызына кадәр йөз чакрым бар диярсең, яктылыкның башы әнә очы кадәр генә булып күренә. Рамазан бөтенләй югалып калды, үз-үзен белештермичә, абына-сөртенә зур гына таш өстенә менеп басты да:

— Мин монда-а-ау! Мин монда-ау! — дип кычкырырга тотынды. Мең тармаклы караңгы юлларның берсеннән кереп китеп, икенчесеннән килеп чыгып күпме йөргәндер, ниһаять, тәмам хәлдән таеп, бер озын яссы таш өстенә килеп ауды. Аның инде атларлык та, уйларлык та хәле калмаган иде. Кесәсенә кәгазьгә төреп тыккан бутербродны Чуфут-калега җәяүләп күтәрелә башлагач ук ашап куйды. Эчәсе килүен сукмак кырыендагы кузгалакларны чәйнәп басты. Кесәләре тап-такыр хәзер. Бу тау тишегеннән исән-имин чыга алса да, үз автобусларыннан калды да калды инде, Ялтага машина-фәлән яллап кайтырга да бер тиен акчасы юк...

Хәсрәтле уйларыннан Рамазанны ниндидер кыштырдаган тавыш айнытып җибәрде. Малай, шомланып, колакларын торгызды. «Чышт-чышт» итә дә, тавыш бер мизгелгә генә тынып тора. Аннары тагын кабатлана. Малай күңелендә: «Минем кебек адашып килеп кергән кешеме, әллә эзләүчеләрнең берсеме?» — дигән зәгыйфь кенә өмет уты уянып куйды. Баягы «кое» авызыннан төшкән яктылык турысына җиткәч, теге тавыш тагын тынып торды. Рамазан, исен җыеп, текәлебрәк караган иде, коты очып, таш ятагыннан авып төшә язды: стенадан, сузылып, бүрәнә юанлыгындагы елан төшеп килә иде! Бу күренеш малайның бөтенләй зиһенен чуалтты, ул, ни үле, ни тере түгел дигәндәй, һәйкәлдәй катып калды. Бик теләсәң дә, кайларга чыгып чабасың? Елан шулкадәр зур һәм дәһшәтле иде, мөгаен, аз гына хәрәкәт ясасаң да, гөрселдәп өстеңә ташланачак! Хәер, аның монда болай да җан иясен сизеп килүедер, туп-туры Рамазан ягына шуышмас иде... Күп дигәндә тагын ике-өч минуттан алар инде күзгә-күз очрашачаклар. Малай, гаҗиз калып, сыгылып төште.

Күпме шулай калтырап утыргандыр, кинәт мәгарә эченә ерактан җирән ут яктысы сирпелеп керде. Рамазан сөенеченнән кычкырып җибәрә язды. Эзләп тапканнар икән, ниһаять, ниһаять... Ут якынлашты, якынлашты, һәм... аның каршында кулына зур фонарь тоткан ят адәм пәйда булды. Рамазан, сискәнеп, утырган җиреннән артка таба шуышты. Ул башта кайсыннан — еланнанмы, әллә бу адәмнәнме сакланырга кирәклеген чамалый алмый иде. Ә теге кеше үтә дә тиз хәрәкәт итте, Рамазанга таба бер генә күз сирпеп алды, мизгел эчендә аның ягыннан елан өстенә таба лазер уты сыман кып-кызыл яктылык сузылып китте. Ут елык-елык килеп берничә мәртәбә кабатланды, ул арада күпмедер вакыт дәвамында каршы яктан ысылдаган, ышылдаган, шапылдаган тавышлар ишетелеп торды. Рамазан, исенә килеп, күтәрелеп караганда, елан тау хәтле булып өелеп, хәрәкәтсез калган иде. Ә коткаручы кем? Дусмы, дошманмы? Качаргамы аның яныннан, ярдәм сораргамы? Ул арада теге адәм малайның янына ук килеп баскан, бөркетнекедәй күзләрен яндырып, аңа текәлгән иде. Үзе бөтенләй дә олы кеше түгел икән, Рамазаннан аз гына калкурак үсмер. Өс-те-башы аңлашылып бетми: әкият киноларындагы геройларныкы кебек төрле төскә кереп елкылдап торган киемендә үтә заманча өстәмәләр. Бик озак торгач карашып... дигәндәй, беренче булып ят малай телгә килде: «Кем син? Каян килдең?» Аннары алар арасында ярым ымлап, ярым сүз белән шундыйрак «сөйләшү» булып алды: «Юлдашларымнан адашып калдым. Булдыра алсаң, күрсәт миңа юлны». «Юлдашларың кай тарафта калды?» «Белсәм, синнән ярдәм сорар идемме?» Аннары Рамазан яңа танышының Баһадур исемле булуын, аның «мәгарә шәһәре»ндә яшәгәнлеген, вакыт-вакыт шулай тау лабиринтларында сәяхәт кылып йөрергә яратканлыгын белде. «Мин синең тавышыңны ишеттем, тик эзеңә тиз генә төшә алмадым,— дип аңлатты Баһадур.— Ә син менә елан өненә барып кергәнсең. Әздән генә калдың бит...» Ул үзе татарча сөйләшә кебек, әмма һәр сүзне бозып, боргалап әйтә, бөтенләй аңлашылмый торган сүзләр дә куллана. Рамазан аның нәрсә турында фикер йөрткәнен күбрәк кул хәрәкәтеннән чамаларга тырышты. Әмма

«мәгарә шәһәре»нең ни икәнлеген дә, бу малайның кайсы милләт кешесе булганлыгын да төшенә алмады.

— Мин сине җир өстенә озатып куярмын,— диде Баһадур, Рамазанның хәлен аңлагач.— Әмма бүген түгел. Син инде бик ерак киткәнсең, бер-ике сәгать эчендә генә юлдашларыңны куып җитә алмассың. Анда озакламый караңгы төшә, үз шәһәрегезгә бара торган юлны да таба алмассың.— Шулай дигәч, Баһадур аз гына уйланып алды.— Безнекеләр Җир өсте кешеләрен яратып бетермиләр үзе. Алар начар уй алып керәләр. Без алардан бик азапланабыз...

Иярсә дә иярде, иярмәсә дә иярде Рамазан Баһадур артыннан. Башка чарасы бар идемени соң! Аннан калмаска тырышып сөрлегә-сөрлегә атлады. Бер-берсеннән берни белән дә аерылмый торган мең төрле юл арасыннан кирәклесен ничек таба ала икән соң бу тау малае? Үзе шулчаклы җитез кылана, аяк астындагы түмгәкләрне ансат кына аралап, мәче сыман сикерепсикереп атлый. Аннары, туктап, мышкылдап беткән Рамазанны көтеп ала. Бара-бара шактый юл алдылар, барган саен йә аскарак төшәләр, йә өскә таба күтәреләләр кебек тоелды Рамазанга. Кайбер урыннарда юл шулкадәр тарая, малайларга хәтта түшләрендә генә шуышып чыгарга туры килә. Ниһаять, алда куе сары яктылык күренә башлады. Ул торган саен киңәя барды. Шуңа таба төбәп бара торгач, малайлар лифт ишекләренә охшаш зур капка төбенә килеп төртелделәр. Баһадур яшькелт ут чәчеп торган түгәрәк төймәгә басты, капка ачылып китте, һәм Рамазан аның теге ягында үзләрендәге кебек тимер рельслар өстендә басып торган, әмма шактый кечкенә поезд вагонын күреп алды. Аның эченә күп дигәндә өч-дүрт кеше сыядыр. «Утырабыз!» — дип ымлады Баһадур. Шул мизгел эчендә Рамазан әллә ничә төрле халәт кичерергә өлгерде. Курку да, кызыксыну да, аптырау, шикләнү дә... Вагон стенасындагы яшькелт төймәләргә берничә тапкыр басып алу җитте, йөртүчесез-нисез килеш ул тавышсыз гына кузгалып китте дә дөм караңгы лабиринтлардан җай гына тәгәри башлады. Ун-унбиш минут вакыт узды микән, Баһадур: «Килеп җиттек»,— дип белдерде. Вагон ишегеннән чыгуга, Рамазан алдында чын-



чынлап әкият дөньясы ачылган кебек булды. Ул очыкырые күренмәгән галәмәт зур киңлекне биләп алган цирк бинасы эчен хәтерләтә иде. Өстә, биектә-биектә, аллы-гөлле утлар җемелдәшә, алар төрле зурлыктагы, төрле рәвештәге йортларны төрле төскә кертеп яктырталар. Ул йортлар мәгарә стенасын уеп ясалган кебек, шул ук вакытта зәвыклы, курчак өйләре кебек матур. «Алар бик борынгыдан калган, еллар үткән саен заманга яраклаштырылып үзгәртелә генә барган,— дип аңлатты Баһадур, Рамазанның сәерсенеп карап торуын үзенчә аңлап.— Безнең йортлар мәңгелек. Моннан мең еллар чамасы элек, яу килгәч, бабаларыбыз җиңеләселәрен аңлаганнар һәм, дошманга калмасын өчен, корылмаларны җимермәкче булганнар. Тик булдыра алмаганнар... Мәгарәнең һавасы да сездәгечә түгел. Монда янгыннар да була алмый, җир тетрәү дә зыян салмый». Баһадур боларны бик тәмләп, кулларын изиизи сөйли. Яңа танышының сәерсенеп, авызын ачып тыңлавыннан ләззәт ала, күрәсең. Рамазанга, дөрестән дә, болар кызык, бик кызык. Әмма ул кисәктән өстенә ишелеп төшкән бу кадәр дә гаҗәеп хәлләрдән башы әйләнеп, миңгерәүләнеп калгандай булган иде.

Менә-менә уянып китәр дә һәммәсе дә юкка чыгар кебек тоела иде аңа. Бая елан белән очрашканда, һай теләгән иде ул шулай булуын. Хәзер алай уйламый... Хәер, ни уйлаганын үзе дә белми бугай инде ул.

Төнге Ялтаның бер почмагына килеп эләккән кебек тә хис итте үзен Рамазан. Монда да җир өстендәге кебек тормыш кайный, аерма шунда — шәһәр урамнарында елкылдап торган уңайлы киемнәргә төренгән матур йөзле, төз гәүдәле кешеләр генә күренә, һич кенә дә машина ише нәрсә күзгә чалынмый. «Алары — шәһәр астындагы юлларда»,— дип аңлатты Баһадур. Бер йорт яныннан узганда, анда төшеп-менеп йөри торган махсус урынны да күрсәтте.

* * *

Баһадурның әти-әнисе Рамазанга башта шактый гына сынап карап тордылар. Малайларын шелтәләгән кебек тә булдылар. Аннары аңлаштылар, күрәсең, кунакны зәвыклы итеп бизәлгән аш өстәле янына алып килделәр. Нинди генә сый-нигъмәт юк иде монда! Кайберләрен Рамазанның беренче күрүе, беренче тапкыр татып каравы иде. Өстәл артында Баһадур Рамазан белән ничек очрашулары турында сөйләде. Тегеләре аны тиргәмәделәр генә түгел, хуплап та куйдылар әле. «Ул хәшәрәт еланнар күпме кешенең башына җитте инде»,— диештеләр.

Ашап-эчкәч, Рамазанның күңеле күтәрелеп, тынычланып китте. Ул Ялтаны, анда калган әти-әнисен исенә төшерде. Нишлиләр икән инде алар? Ул монда кәеф-сафа корып утыра, ә алар анда, бөтен Кырымның астын өскә китереп, малайларын эзлиләрдер... Иртәгә әнисе белән очрашу мизгеле күз алдына килгәч, Рамазан куырылып куйды.

Казанда чагында Рамазан никадәр тарих, география китаплары, том-том энциклопедияләр актарды, «мәгарә шәһәрләре» турында да әллә никадәр мәгълүматы бар иде. Әмма ул шәһәрләрдә бүгенге көндә дә яшәп ятулары мөмкиндер дигән уй малайның башына да килеп карамады. Дөрес, мондагы тормыш ул укып белгән, инде ерак тарихта калган нәрсәләргә якын да килми: имеш, бик борынгы заманда бу җирләр то-

таш диңгездән торган, хәзерге таулар ул чагында утрау булганнар. Кешеләр шул утраулардагы мәгарәләрдә яшәгәннәр, бер-берләренең торакларына көймәләрдә йөзеп килә торган булганнар. Шул вакытлардан соң миллион еллар узган. Су кимегәч, таулар күтәрелгән, Кырым үзе утрау булып калыккан. Кыяның өске өлешендәге куышларның ишек-тәрәзәләре таш, түбәнрәкләренеке тимер кораллар ярдәмендә эшләнгәннәре билгеле. Кырым таулары борынгы диңгез астында формалашкан, утырма токымнар, известьташ, комташ, сланец, кызыл балчык миллион еллар дәвамында бергә оешып, аннары, судан өскә күтәрелгәч, җил-давылларда чыныккан да утка-суга чыдам хәлгә килгән. Ә тау башындагы чакырылмаган кунаклардан саклану өчен төзелгән ныгытмалар безнең көннәргәчә сакланып калган. Соңрак, инде йортлар төзеп яши белә башлагач та, кешеләр мәгарәгә сукмакларын өзмәгәннәр, борынгы гыйбадәтханәләргә йөрүләрен дәвам иткәннәр. Чөнки аларда серлелек, илаһилык җир өстендәгеләренә караганда күп тапкырлар артыграк, тормыштан сүрелеп, сүнеп барган кешеләр дә монда үзләренә яңа көч, рух алып чыгалар икән. Мәчетләр дә, чиркәүләр дә бертигез сакланган, димәк, бер үк вакытта мөселманнар да, христиан халкы да яшәгән дигән сүз бу мәгарәләрдә...

Тукта, тукта, Баһадурларның сөйләше безнекенә бик охшаш бит, һәрхәлдә, аңлашып була, уйлап карасаң, үзебезнең татар нәселедер дә әле ул, Кырым татарлары нәселедер... Әмма ник болай яшәп яталар икән соң алар, җир өстендә урын беткәнмени? Хәзер бит Кырым диңгез түгел. Аннары элек шул куышларны кешеләр йорт дип атаганнар, ә боларның гигант куышлар эчендәге тораклары бездәгедән дә матур, цивилизацияләре дә безнекеннән һич ким түгел, артыграк булмаса әле... Шул сорауны Баһадурга биргән иде, ул моны көткән булган, күрәсең, очына-очына тагын сөйләргә тотынды:

— Безнекеләрнең анда яшәп караганнары бар. Анда — сугыш, кан... Без андый тормышны аңлый алмыйбыз. Сез бит яшәргә өлгерә дә алмый каласыз. Бөтен гомерегезне талашып уздырасыз. Һәммә нәрсәләре җитеш кешеләр дә анда үзләренә үзләре һич кирәксез мәшәкатьләр уйлап таба. Дуслар бер-берсен

сата, бер ата-ана балалары үзара дошманлаша. Һәркемгә һәрвакыт нәрсәдер җитми. Барысы да көнчелектән, башкалардан өстенрәк буласы килүдән. Безнең алай яшисебез килми. Синең кебек адашып килеп кергәннәр бар монда. Күбесе үз җирләренә кабат кайтырга теләми. Ә китәргә уйлаганнарны тотмыйбыз. Тик кире кайтканда, үзебез генә белә торган юлдан чыгарып куябыз, икенче кабат килергә теләсәләр дә, мәңге булдыра алмыйлар. Бүтәннәргә сөйләсәләр дә, аларның «әкияте»нә берәү дә ышанмый. Без үзебез дә җир өстендәгеләр белән аралашырга атлыгып тормыйбыз. Болай да тыныч яшәргә ирек бирмиләр алар безгә...

Шулай дигәч, Баһадурның йөзе ничектер сүрелеп куйды.

...Иртән Рамазан күзләрне чагылдыра торган яктылыкка уянып китте. Төнгә шәһәр урамнарындагы утларны сүрелдерәләр, күрәсең. Йомшак түшәктән аерыласы килмичә иркәләнеп ятканда, кичәге вакыйгалар маҗаралы төш кебек бер-бер артлы күз алдыннан үтте. Юк, төш булмаган икән ул, әнә янында Баһадур да нәкъ кичәге кебек елмаеп басып тора.

— Әйдә, юлга чыкканчы, мин сине «Җир өсте»нә алып менеп төшәм, аны да күреп китәрсең,— диде ул.

«Җир өсте» дигәненә менү өчен дә махсус җайланмалары бар икән. Анысын лифт дип әйтсәң дә ярый торгандыр. Кара-каршы эскәмияләр куелган булуы белән генә үзгәрәк. Төймәсенә баскач, бездәге кебек дөбер-шатыр кузгалып китмәде ул, җай гына очыртып алып менде. Ярты сәгатьләп вакыт узгандыр, килеп туктауга, лифт ишекләре ачылды, һәм Рамазанның урам ягындагы хозурлыктан хәтта җиңелчә генә башы әйләнеп киткәндәй булды.

Шау чәчәккә төренеп утыручы киң дала Кырым кояшының алтынсу нурларына күмелгән. Еракта калын-калын урманнар шәйләнә, алар артында челтәрләп эшләнгән биек ныгытма стеналары калкып утыра. Рамазан, таң калып, таш түшәлгән тар сукмак буйлап алга таба атлады. Анда үтә күренмәле зәп-зәңгәр сулы күл икән, әллә кеше кулы белән ясалган бассейнмы? Суда чыр-чу килеп бала-чага шаярыша, яр кырыендагы комлыкта кызынып ятучылар да күп. Рамазан сихерләнгән кебек барды да барды, ә Баһадур уйнаклый-



уйнаклый аның артыннан атлады. Бара торгач, алар киң җәйләүгә килеп чыктылар, колакка ат кешнәгән, чыбыркы шартлаткан тавышлар килеп керде.

— Без «Җир өсте»нә кояштан көч алырга, табигать белән аралашырга чыгабыз,— дип аңлатты Баһадур.

— Шулайдыр шул. Гомер буе таш арасында яшәү кыендыр.

— Кыен түгел! Мәгарә һавасының безгә һич зыяны юк. Температура да җир өстендәге кебек тирбәлми бит монда. Җәен салкынча, кышын, киресенчә, җылы була. Ә монда — яшеллек, су, урман... Һәрберсе үз урынында кирәк.

Кайтыр юлга борылгач, Рамазан икеле-микеле уйлар эчендә атлады. Бер көн югалып тордың ни дә, ике көн булды ни... Әнисеннән барыбер шәп кенә эләгәчәк инде аңа. Ә монда әле аның «Җир өсте» урманнарында йөреп кайтасы, бассейннарында су коенып карыйсы бар. Баһадурга ияреп, тау лабиринтларына да чыгып керсәң... Казанга кайткач, иптәшләрен шаккатырыр иде сөйләп. Ышанмаслар гына инде түлке... Бу хакта Баһадурга әйткән иде, тегесе иңнәрен генә сикертте. Үзеңә кара инде, янәсе.

Лифтта яшькелт күзле, көләч йөзле кыз белән бергә туры килделәр. Су кереп кайтышы икән.

— Күрше кызы,— дип таныштырды аны Баһадур, үзе никтер аңа өнәмичәрәк карап куйды.

— Алай гына түгел, якташы да әле мин аның,— дип чытлыкланды кызый. Монда да «ватык телефон» шәп эшли, ахры, Рамазан турындагы хәбәр таралып өлгергән булса кирәк.— Сиринә минем исемем. Самарадан класс белән килгән идек. Икенче ел китте инде монда килеп эләккәнгә. Кайтасы килми. Бу рәхәттән кемнең качасы килсен!

Сиринә белән сөйләшү Рамазанның икеләнүле уйларын артка чигерде. Кыз башы белән калган бит әле менә! Үзе бик чая күренә:

— Кал син дә! Аннары бергә кайтып китәрбез,— дип, Рамазанны ныклап торып өнди башлады.

Мөгаен, шулай эшләр дә ул. Бер киткәннәр кире табып керә алмый, ди ич әнә Баһадур да. Гомер эчендә бер генә була торган хәл бит бу...

* * *

Ничә көн, ничә төн узды икән инде Рамазанның мәгарә шәһәрендә яши башлавына? Өч көннән китәм, бер атнадан китәм, дип йөри-йөри, вакыт исәбен дә онытты бугай инде ул. Көн туган саен, бер яңалык туа, шуңа алданып, кайтырга кирәк, дигән уе тагын

арткарак күчә. Бәһадур белән аларның көндәлек шөгыле — җәйләүгә менеп атлар эчерү, урман эченә кереп, җиләк-җимеш җыеп кайту. Җәйләү дигән нәрсәне кинодан гына күреп белгән шәһәр малае бит ул. Берничә көн эчендә дуслашып та өлгерде бахбайлар белән. Бәһадур аны атка атланып йөрергә өйрәтте. Җил белән узышып җилдереп барганын күрсәләр, шәһәрдәге иптәш малайлары көнләшүдән шартларлар иде, мөгаен. Юкса, «башың зур, беләгең сыек» дип, гел мыскыл итәргә генә торалар.

Ныгытма кырыена килеп, озак-озак карап торырга да ярата ул. Кай тарафка күз салма — төрле формадагы гигант таш кыялар калкып утыра, еракта-еракта диңгез шәйләнә. Ныгытма астындагы кыя-ташлар өстен кара болыт кебек каплап тау бөркетләре утыра... Аннары Рамазан мәгарә китапханәсенә бара, комсызлана-комсызлана өстәл зурлыгындагы калын китапларны актара. Билгеле, күбрәк рәсемнәрен карый, шулар аша да башына әллә никадәр мәгълүмат җыйды инде. Укуы кыенрак, Казанда чагында латин графикасын әйбәтләбрәк үзләштергән булса шунда! Хәрефләрен берәмләп чүпли торгач, хәйран бара тагын үзе. Күп нәрсә аңлашылмаса да, булган кадәресе дә бик кызык аның өчен. Әмма шунысы бар: китапханәгә кергәндә дә, чыкканда да махсус тикшерү аппараты аша уздыралар, бер генә кәгазь кисәге дә сиңа ияреп чыгарга тиеш түгел. Бар укыганыңны башыңа салып чыга алсаң гына инде. Әбүгалисина белән Әбелхарис шикелле...

Кайчакларда теге таныш вагонга утырып, Бәһадур белән тау лабиринтларында сәяхәт кылып кайталар. Беркөнне аларга талаша-талаша диярлек Сиринә дә иярде. «Анда сиңа берни дә калмаган»,— дип, Бәһадур каршы килеп маташкан иде үзе. Ул аны яратып бетерми, «кирәкмәгән җиргә кысыла» дип зарлана. Бәһадурның үзен дә аңлап бетерү кыенрак кайчакта. Күп сөйләшә торган гадәте булса да, ни теләгәнен турыдан-туры әйтми, башлаган сүзен дә күп вакыт «йотып» калдыра. Рамазан: «Бер юлга барсын инде»,— дип, Сиринәне якламакчы булган иде, Бәһадур «ә» дә, «җә» дә димәде, әллә риза булды, әллә — юк, капыл гына кузгалып, вагон ягына таба китте дә барды. Юл

буе Сиринәгә бер авыз сүз дәшмәде, аны бар дип тә белмәде. Хәер, Сиринә үзе дә моны әллә ни авыр кичермәде шикелле, юл буе Рамазанны шаяртып, аның белән үртәшеп барды. Ул көнне алар әкияти патша сараена охшаган зур, мәһабәт тау куышындагы мәгарә күленә бардылар. Куыш эче ярыйсы гына салкын, стеналардан, түшәмнәрдән үтә күренмәле озын-озын боз сөңгеләре асылынып тора, алар әлеге дә баягы «кое» тишекләреннән төшкән яктылыкта аллы-гөлле булып күренәләр иде. Бөтен тирә-юньгә бәллүр бизәкләр төшерелгәнмени! Су тамчылары, яңгыравык тавышлар чыгарып, чупыл-чупыл югарыдан идәнгә тама. Күлгә якынрак килеп, суга кулларын тыгып караганнар иде, дәррәү аһылдашып куйдылар. Су боз кебек салкын булып чыкты. Шулчак Рамазан башын күтәргән иде, Баһадурның нәфрәт тулы карашын Сиринәгә төбәгәнен күреп, сискәнеп куйды. Шундый да ямьсез, җан өшеткеч караш иде ул, аның андый чагын күргәне дә юк иде Рамазанның. Ул мыштым гына ике арага кереп басты. Башында нинди уйлар йөрткәнен белмәссең бу тау малаеның! Ә Сиринә — ни әйтсәң дә, үзебезнеке...

Ә бүген Баһадур Рамазанны патшалар каберлегенә алып барды.

— Беләсең килсә, әүвәл мәгарә шәһәрләрендә патшалар тоташ гаиләләре белән качып ята торган булганнар. Төрле чорда яшәсәләр дә, каберлек бер...

Каберлекнең бусагасын атлап кергәч тә, Рамазанның йөзенә ниндидер сискәндергеч дулкын килеп бәрелгәндәй итте. Каршысында пәйда булган ят манзарага шактый вакыт сәерсенеп карап торды ул. Стеналардагы тонык яктырткычлардан шомлы күләгәләр сузылып киткән. Пәрәвез ояларына чорналып беткән түшәмнең әле бер почмагында, әле икенчесендә, ят тавышлар чыгаргалап, ярканатка охшаш кошлар бәргәләнә. Идән төрле формадагы, төрле зурлыктагы яссы ташлар белән шыплап тулган. Беркавым шаккатып карап торганнан соң, Рамазан ул шома ташларның берсеннән икенчесенә күчә-күчә озак йөрде. Өсләренә уеп язылган хәрефләрнең тузаннарын сөрткәләп, ниләр язылганын укырга азапланды. Алдан хәзерлегең булмагач, кыенрак шул. Тарих укытучысы белән кереп адашкан булсалар менә...

— Монысы — безнең җиденче буын бабабызныкы,— диде Баһадур, урта бер җирдә урын алган кабер ташы янына килеп.— Әхмәт ханныкы. Аның турындагы риваятьне сөйлимме сиңа? Тыңлыйсыңмы?

Тыңламыймы соң инде Рамазан! Һәр яңалыкны йотлыгып тыңлый, һәр нәрсәне ашардай булып карый. Әлеге дә баягы, шунысы кызганыч, кулга каләм алырга рөхсәт юк. Бар нәрсәне шул кеп-кечкенә башка сыйдырып бетерергә кирәк.

...Әүвәл кешеләр хәзер Баһадурлар яши торган гигант тау куышында түгел, җир өстенә якынрак булган куышта яшәгәннәр. Ул чакта монда Гәрәй хан идарә иткән. Гәрәй ханның Зөләйха исемле бик гүзәл кызы булган. Үсеп буйга җиткәч, аңа диңгез артында яшәүче икенче бер ханның бу якларга сәяхәт итәргә чыккан улы гашыйк булган. Зөләйха, тау куышыннан чыгып, көн дә шул тирәдәге чишмәгә суга йөри икән. Аның матурлыгына бар табигать сокланган, ул йөргән эзләрдә берсеннән-берсе матур болын чәчәкләре үсеп чыккан, ди. Егет тә төшеп калганнардан түгел, чибәрлеге өстенә, баскан җирендә ут чыгара торган гаярь зат икән. Шулай очрашып йөри торгач, болар бергә булырга карар кылганнар. Әмма Зөләйха хан малаена ияреп китәргә теләмәгән, егет тә мәҗбүр итмәгән, чөнки атасының явызлыгы бөтен тирә-юньгә мәгълүм икән, читтән кыз алып кайтуын кичермәслеген аңлаган. Шулай итеп, егет мәгарә ханлыгында яшәп калган. Озакламый аларның Әхмәт атлы уллары туган. Гәрәй хан оныгын бик яраткан, аңа җырлый торган бишек бүләк иткән. Шулай матур гына яшәп ятканда, диңгез арты ханы мәгарә ханлыгына каршы бик зур яу җибәргән: улының чит ханлыкта яшәп ятуын күтәрә алмаган. Көрәш каты булган. Мәгарә ханлыгының сугышка әзерлексез гаскәре дошманга озак каршы тора алмаган. Гәрәй ханның курку белмәс кияве, хатынын һәм улын яклап, үз кардәшләренә каршы киткән. Әмма күп мәртәбәләр җиңүгә ирешсә дә, ялгыз сугышчы тигезсез бәрелештә батырларча һәлак булган. Карт хан, кызы белән оныгын алып, үзе генә белә торган җир асты юлыннан качып китмәкче булган. Ул юл тауның икенче ягына алып чыгарга тиеш икән. Әмма рәхимсез дошман моны си-

зеп алган, коры-сары җыеп китереп, алар кереп киткән юл авызына ут төрткән. Тончыктыргыч төтен исе качкыннарны куып җиткән, шулай да Гәрәй хан Әхмәтне бишеге белән тау куышыннан этеп чыгарырга өлгергән. Исән калган кардәшләре бишек тавышын ишетеп (аны җырлый торган дип әйткән идек бит), баланы табып алганнар.

— Бүгенге шәһәребезгә дә беренче башлап шул афәттән исән калган Әхмәт хан килеп утырган, үзенең нәселен шулай дошман күзеннән ераграк яшерергә тырышкан,— дип аңлатты Баһадур.— Шуңа да безне «Әхмәтнекеләр» дип йөртәләр. Чуфут-каледа хәзер мондый шәһәрләр йөзләгән.— Аннары бераз уйланып торды да:

— Әйдә, чыккан-чыккан, тагын бер җиргә алып барып киләм мин сине,— диде.

Бу юлы шактый озак атладылар. Рамазанның фонарь тоткан кулы талып бетте. Баһадур үзе яктырткычын шахтерлар кебек маңгаена каеш сыман нәрсә белән беркетеп куйган иде. Аны салып, Рамазанга киертте. Үзе:

— Болай озак йөрербез дип уйламаган идем,— дип, аклангандай әйтеп куйды.

Рамазан сизеп тора: Баһадурга аның алдында үзен гид итеп тою бик ошый. Сорауларына бик тәмләп җавап бирә. Рамазанның гаҗәпләнгәненнән кызык таба. «Синең белән рәхәт»,— дип әйтеп куйганы да бар. «Син батыр малай»,— дип, салпы ягына салам кыстырып та куя. Алай ук түгел инде үзе. Теге чакта елан белән очрашканда курыкканнары!.. Аннары, янында Баһадур булмаса, бу мәгарә сукмакларыннан ялгызы гына йөрер идеме икән? Ай-һай! Тик менә күпме генә ялынса да, белгәннәрен язып куярга рөхсәт итми. «Язганнарың дошман кулына төшсә, мин хыянәтче булып чыгам бит»,— ди. Дошман кулына төшмәячәгенә Рамазан аны һичничек ышандыра алмый.

Бара торгач, мәһабәт таш капка каршына килеп чыктылар. Әкият иленә килеп керделәрмени! Мондый нәрсәне Рамазанның кинода гына күргәне бар. Баһадур да нәкъ шул әкият киносындагы кебек кыланды: стенадагы тешле зур ташны көчәнә-көчәнә әйләндерде дә, теге таш капка поезд вагонының купе ишеге кебек стена эченә шуып кереп китте. Аңа карап кына

капка бусагасын атлап кереп булмый иде әле, мәгарәне тагын тимер челтәрдән эшләнгән стена каплап тора иде. Баһадур бу галәмәткә хәйран калып карап каткан Рамазанны,уятырга теләгәндәй, җиңеннән тарткалап алды.

— Әнә тегендә кара син!

Ә анда, тимер челтәр артында... Рамазан бөтенләй телсез калды. Теге чакта, әти-әнисе белән Севастополь каласына экскурсиягә баргач, сугыш кырын сурәтләгән панорамага кергән иде алар. Шулкадәр оста ясалганлыгына гаҗәпләнеп, сокланып чыктылар. Сугышчыларын чын кешеләрдән аерып алып та булмый хәтта. Монысы да рәссам кулы белән ясалган нәрсәдер, дигән уй сызылып узды малайның башыннан. Таш стенага сөялеп утырып хәрәкәтсез калган бер төркем кеше сыннары иде монда. Ир-атлар бер тирәгә чүмәшкән, гүя ни хакындадыр сөйләшәләр, киңәшәләр. Хатын-кызларның итәкләрендә — яшь балалар, алар да әниләренең күкрәкләренә сыенып катып калган. Кием-салымнары бездәге кебек тә, Баһадурларныкы сыман да түгел. Якынрак килеп, сыннарга кагылып карарга иде менә... Баһадур гигант читлек эченә кереп китәрдәй булып үрелеп карап торган Рамазанның җилкәсенә авырттырып төртеп алды:

— Ачкычы — шәһәр башлыгы кулында, керәсең килсә, җиде елдан кабат килерсең,— дип көлде.— Алар монда дошман явыннан яшеренеп калмакчы булганнар. Бу моннан ике йөз еллап элек булган хәл. Аларны эзәрлекләгәннәр, тапканнар, шушында томалап калдырганнар. Ачлыктан үлгән булсалар кирәк... Әмма бу тау куышында һава бик үзенчәлекле, монда бөтен нәрсә беркайчан да бозылмый саклана. Безнең галимнәр бу кешеләр өчен тиешле шартлар тудыру өстендә эшләделәр. Алар тагын җиде елдан терелергә тиеш. Шуннан соң ни булыр — безнекеләр инде моны күптән зарыгып көтә.

Җиде ел... Күбрәк икән шул әле. Кызыксынуы чиктән ашса да, алай ук тора алмас Рамазан монда. Кайткач, ни дип аңлатырсың? Ышанмаслар, тиле, дип көләрләр. Көлеп кенә калсалар әле...

Кайту юлында Рамазан бетмәс-төкәнмәс сораулары белән Баһадурны йөдәтеп бетерде:

— Ни өчен адәм эзләп таба алмаслык җирдә яшәвегез аңлашыла инде. Ә «Җир өсте»н ничек саклыйсыз? Дөньяда сезнең кебекләр барлыгын ничек безнекеләр белми икән соң?

— Беләләр, ышандыра алмыйлар. Дәлилләре юк. Шуңа күрә белгән кадәресен дә яшерергә мәҗбүрләр...

Бу сөйләшүне Рамазанга берничә көн узуга ук кабат искә төшерергә туры килде. Ул иртәне алар Баһадур белән гадәттәгечә җәйләүгә барырга дип кузгалганнар иде. «Җир өсте»нә чыгып басуга, ыгы-зыгы килеп чабышкан кешеләр төркеменә юлыктылар. Шунда ук колак тондыргыч итеп чаң суга башлады. «Яу килә!» — дип кычкырды Баһадур, ныгытма стенасына таба йөгереп. Ул арада «Җир өсте» төрле яклап вертолет гөрелтесенә күмелде. Ныгытма стенасын халык сырып алган иде, учларын авызларына куеп, әкәмәт тавыш белән кычкыра, сызгыра башладылар. Шулчак аскы яктан кара болыт булып тау бөркетләре күтәрелде дә, ук кебек атылып, өерләре белән вертолетларга ташландылар. Бөркетләр шулкадәр күп иде, әллә ничәшәр катланып ябырылгач, «тимер кошлар» мондагыларга бөтенләй күренмәс хәлгә килде. Менә өстән ату тавышлары яңгырый башлады. Берничә бөркет шапылдап җиргә егылып төште. Моңа карап башкалары таралмады гына түгел, вертолеттагыларга тагын да дәһшәтлерәк итеп, зур ашъяулык кадәр канатларын ярсып җилпи-җилпи, яман тавышлар чыгарып кычкыра-кычкыра ташландылар. Бу гарасат ярты сәгатьләп дәвам иткәндер, мөгаен. Инде вертолетлар кайту ягына борылгач та, бөркет көтүе аларны хәйран озата барды әле.

Ул көнне дә, аннан соң да мәгарә эчендә уен-көлке беразга онытылып торды. Каты бәрелештә берничә бөркет һәлак булган иде, аларны чын сугышчылар сыйфатында тантаналы рәвештә җирләделәр. Яраланганнарын махсус күзәтү астына алдылар.

— Мондый хәлләр бездә әледән-әле булып тора,— дип аңлатты Баһадур күңелсез генә.— Моннан бер ай элеккесендә минем туганнан туган абыем һәлак булды... Яраланган бөркет янына йөгереп барган җиреннән пуляга эләкте...



— Нәрсә инде бу? Сезгә аталар, ә сезнең үзегезнең сугыш җайланмаларыгыз да юк! Үч аласыгыз килмимени сезнең?

Рамазанның капылт кабынып китүенә Баһадур да җавапсыз калмады, һәр сүзенә басым ясый-ясый аңлатырга тотынды:

— Беренчедән, «үч» дигән нәрсәне мин бөтенләй аңламыйм! Икенчедән, сугыш җайланмаларыбыз бар икәнлеген син теге хәшәрәт елан белән алышкан чакта ук күрдең инде. Кирәк тапсак, аларын да эшкә җигәрбез!

— Сезнеңчә, кайчан кирәк була соң ул? «Патриотизм», «Ватан алдындагы бурыч» дигән төшенчә юкмыни сездә? Сугыш вакытында бездә олылар гына түгел, балалар да дошманга каршы күтәрелгән. Хәзер дә безгә илне саклауның изге бурыч икәнлеген өйрәтәләр. Ә монда?.. Ныгытма стеналарына сыланып, «бөркет сугышы»на читтән генә карап торасызмыни?

— Кешеләр бер-берсенә утлы корал белән килергә тиеш түгел ул! Киләләр икән, бу гамәлләре өчен бөек көч алдында үзләре җавап бирәчәк. Без дә алар кебек кылансак, нәрсә булыр иде? Күз алдыңа китер. Астан да, өстән дә пулялар бөркет көтүенә тияр иде. Тау бөркетләре — безнең дусларыбыз, ышанычлы сакчыларыбыз, инде ничәмә-ничә гасыр буе шуңа өйрәнгәннәр, дошманнарын җиңмичә торып, аларны сугыш кырыннан болай гына куып җибәреп булмый. Монда бит сезнең самолетлар барыбер менеп җитә алмый, ә вертолетларыгыз, өерләре белән килсәләр дә, безнең куркусыз бөркетләребезгә каршы тора алмыйлар. Кангакан белән җавап бирү әйбәт гамәл түгел ул, Рамазан! Кеше гомеренә тыкшынырга берәүнең дә хакы юк!

* * *

Беркөнне Рамазан гадәттәгедән иртәрәк уянды. Гомумән, монда яши башлаганнан бирле иртүк торалмый азапланганы юк аның. Әнисе янында булса, әй, куаныр иде. «Төн буе компьютер төбендә утырасың да, иртән торгыза алмый җәфаланам»,— дип, гел тиргәп тора ул аны. Монда да компьютер залы бар, әмма анда билгеле бер вакыт аралыгында гына керергә рөх-

сәт итәләр. Рамазанның җене сөйми торган катгый тәртипләр бар инде монда анысы. Иртәнге сәгать алтыдан ук, мәсәлән, биредә ыгы-зыгылы тормыш башлана. Кемдер төнгә чаклы аяк өсте йөргәндер, аның ял итәсе киләдер, дигән уй берәүнең дә башына килми, шаулапмы-шаулыйлар. «Кичкесендә теләсә ни эшлә, анысы әһәмиятле түгел, ә иртәнге йокыдан кеше билгеле бер вакытта торырга тиеш,— дип аңлатты Баһадур бу хакта.— Озак яшисең килсә, билгеле». Теләсә ни вакыт аяк өсте ашап йөрү дә юк. Анысы да режим белән. Бала-чагасы да сорап аптыратмый, шаккатырсың менә! Белмим, ник шулчаклы азапларгадыр үзеңне?

Нихәл итәсең, кунак булсаң, тыйнак буласың инде. Кунак дигәннән, аның исенә кылт итеп тагын Сиринә килеп төште. «Кунак була белми»,— дигән иде Баһадур аның турында. Ник шулкадәр яратмый икән соң ул аны? Гап-гади кыз инде югыйсә, нәкъ безнең Казан кызлары шикелле. Терелеге дә, чаялыгы да бар. Җебеп, елап утырсынмыни? Өстәвенә, бик сөйкемле дә...

Кемне уйласаң, шул каршыңа чыгар, диюләре хак, ахрысы. «Җир өсте»нә күтәрелеп, бассейн ягына борылган иде, Сиринә күренде. Бик иртә булуга карамастан, инде су кереп чыгарга да өлгергән. Кояш кебек балкып елмая үзе, килеп җиткәч, яшькелт күзләрен хәйләкәр кыскалап, кочаклап күреште.

— Ярый әле, син килдең, бу кыргый затлар янында шашып үләрсең,— ди.

Кызык ул Сиринә. Юк-юкта гел яңа нәрсә уйлап чыгарып кына тора. Монда килеп эләккәненә икенче ел китте, ди бит әнә, мәгарә шәһәрен аркылыга-буйлыга йөреп чыгарга өлгергән инде. Рамазан өчен үзе гид булып йөри ала хәзер.

— Җир астындагы җир астын күрәсең киләме? — дип көлә әле дә.— Минем хуҗамның машинасы бар, шуңа утыртып, бер әйләндереп килим әле үзеңне.

Сиринәне узган ел Ибраһим атлы мәгарә кешесе табып алган. Ул аны «хуҗам» дип атый, тегесенә дә шулай ошый булса кирәк. Аның Зөбәрҗәт исемле бәләкәй кызы белән агылыйга-тагылый булып йөриләр хәзер. Ибраһим абзый аңа нәрсә алып бирсә, Сиринәне дә өлешсез калдырмый.

Машина дигәне безнең «Ока»дан да бәләкәйрәк нәрсә икән. Ике кеше генә сыешлы. Сиринәнең руль артына кереп утыруы булды, шуып барган кебек кенә кузгалып та китте.

— Ай-яй, шушы куыш эчендә яшәп, нәрсә генә уйлап табып бетермәгән болар! — дип тел шартлатты Рамазан.— Вәт баш та соң үзләрендә!

— Нинди баш ди ул! Алар бит бөтен нәрсәне бездән өйрәнә. Ну, башлангычын дип әйтүем инде... Бер уйлап табылганга өстәп җибәрү кыенмыни... Карале, Рамазан, болар хакында Баһадур бер дә сөйләмимени сиңа? Дус булып йөри тагын! Вәт, җен малае. Бернәрсәнең дә артыгын селкемәс.

— «Селкемәс» дип... Ияртеп йөри бит. Күрмәгән нәрсә дә калмады бугай инде.

— Әллә синең өчен йөри дип беләсеңме? Үзенә кызык аның. Әй, ярата да инде мактанырга! Баштарак мине дә алып йөртә иде. Хәзер генә борчак пешми башлады. Вак-төяк нәрсәләре югалгач, миннән күрде. Сиңа гына әйтсәм инде... Түлке сатма, яме. Дөрестән дә мин алган идем, үзебезгә кайткач күрсәтергә дип. Рас үзе белеп бирми инде...

Рамазан уйланып алды. Урлашу әйбәт нәрсә түгел дә, Сиринә сүзләрендә дә хаклык бар. Үзләре бездән өйрәнгәч, безгә дә аларныкын белергә ярыйдыр бит. Теге бүрәнә юанлыгындагы еланның читтән торып башына җитә алган корал турында, мәсәлән. Үзйөрешле вагон схемасын үзләштерсәң дә ярар иде. Баһадур янында гел тел шартлатып шаккатып кына йөрергә дигән микәнни?..

Ул көнне алар бер шәһәрдән икенчесенә күчә-күчә шактый озак югалып тордылар. Аларда искитәрлек әллә ни аерма күрмәделәр. Шуңа күрә Рамазан бу сәяхәттән зур тәэсирләр белән кайтмады. Алай да Сиринә янында бик рәхәт аңа. «Хәзер нишләргә икән?» дип уйлап азапланасы юк, һәммәсен кызый үзе хәл итә. Әле дә машинасын куяю белән башына тагын бер фикер килде:

— Әйдә, тамак ялгап алабыз да китапханәгә керәбез, мин сиңа бер нәрсә күрсәтәм,— дип, Рамазанны үзе белән ияртеп алып китте.

Бу китап сараеның әле Рамазан күрмәгән әллә ничаклы бүлмәсе бар икән. Бер ишектән кереп, икенче-

сеннән чыгып, озак йөрделәр. Ниһаять, күгәрек исе аңкып торган, стеналарына мәгарә лабиринтлары сурәте төшерелгән кечерәк кенә бүлмәгә килеп керделәр. Монысында кеше әллә ни күп түгел иде. Уртада — галәмәт зур өстәл, аның өстенә эскәтер урынына шундый ук зурлыктагы карта җәеп салынган иде. Якынрак килеп, картаның әле бер, әле икенче ягыннан карады Рамазан, тик бернәрсә дә аңлый алмады. Ул белгән, ул күргән нәрсә түгел иде бу. Сиринә шунда ук аңа ярдәмгә ашыкты.

— Мәгарә каласына керү юлы бу. Бусы — Алушта ягы. Менә монысы — Бакчасарай ягыннан керә торганы. Без шунысыннан кереп адашканбыз инде. Аңладыңмы?

Рамазан, билгеле, берни дә аңламады. Йөзәрләгән, меңәрләгән сыр төшерелгән бу картаны мондагылар үзләре аңлый ала микән әле?! Ул сырлар арасына мәчет манаралары, чиркәү гөмбәзләре, ныгытма стеналары, ике башлы еланнар, тагын әллә нинди хәшәрәтләр, зират капкалары сурәтләре төшерелгән. Картаның озынлыгы гына да унбиш-егерме метрлап булыр. Исәпсез-хисапсыз рәсемнәр энә күзеннән чак кына зурraктыр. Менә шуннан нәрсә аңлап бетереп була ди инде?

Сиринә исә картага түгел, Рамазанның үзенә текәлгән иде. Ул аңа сынап, озак итеп карап торды.

— Син зирәк егет. Мин моны әллә кайчан сиздем инде. Безгә бу картаның күчермәсен алырга кирәк. Эшлибезме шуны?

Рамазан тагы да ныграк аптырады. Бердән, бу әкәмәт картаны кабаттан сызып чыгу өчен ике баш түгел, биш баш та җитмәячәк. Икенчедән, ничек итеп? Китапханәгә буш кул белән генә керергә рөхсәт ителә, яшереп алып керә алсаң да, сызып-бозып утырганыңны күрсәләр... Анысын оештыра алсаң да, моннан ничек алып чыгасың? Ярар, анысы да булды ди, ә мәгарә каласыннан ни рәвешле алып китәсең?

Шул турыда тезеп-тезеп әйтеп күрсәткәч, Сиринәнең йөзе каралып китте, яшькелт күзләрендә зәһәр очкыннар биешеп алды. Рамазан аның мондый чагын сирәк күрә, гадәттә бу халәте кызыйның Баһадур белән сүз көрәштергәндә сизелеп куя. Дөрес анысы, си-

зелеп кенә куя, Сиринә, мөгаен, акыллы кыздыр, үзен тиз кулга ала. Бу юлы да әллә ничек җайсыз итеп күрсенеп куйды, аннары йөзенә сөйкемле елмаю кунды. Ә сүзләре шулай да Рамазанның йөрәген чукып-чукып алгандай итте:

— Син — егет кеше. Сугыш вакытында туган булсаң, партизан булып йөрергә туры килсә, нишләр идең? Тегеләй булса, болай булса, дип торыр идеңме? Монда — җәннәт. Мин үзем генә монда гомер буе яшәргә дә риза. Әмма шушы булдымы эш! Әти-әниеңне, туганнарыңны да шушындый рәхәттә яшәтәсең килмимени синең? Күрәсең бит, монда хәтта канга кан белән җавап бирү гадәте дә юк. Башкалар килеп керсә дә, аларга тимәячәкләр... Картаны ничек күчерәбез, дигән сорауга без бергәләп җавап эзләргә тиеш...

* * *

Аннан соңгы көннәрдә Рамазан Сиринәнең күзенә бик чалынмаска тырышты. Тегендә-монда барабыз, дип, Баһадур килеп дәшкәндә дә: «Бераз ял итим әле»,— дигән булып, ялгызы гына калуны кулайрак күрде. Икеле-микеле уйлары тынгы бирмәде аңа. Шулардан арынырга тырышып, көннәрен урман эчендә үткәрде. Тик юкка гына! Үз-үзеңнән качып була димени инде ул! Урманда табигать нигъмәтләре белән сыйланды, керпе малае белән «куышты», тиен баласы белән «качышлы» уйнады, ишетеп тә белмәгән әллә никадәр үсемлек белән танышты. Ә Сиринә сөйләгәннәр барыбер бер генә минутка да башыннан чыкмады аның. Дөрестән дә, сыңар яфрак та алып кайтып булмаячак бит моннан. Ә үзләре әнә ансат кына чыгалар да керәләр, бездән күпме яңалык ташыйлар. Рамазан Баһадурның әтисен күмәкләшеп ниндидер юлга озатуларын үз күзләре белән күреп торды. «Галиханнарныкына барып кайта»,— диде Баһадур, мәгарә шәһәрләренең берсен атады. Ул моны Рамазанга күтәрелеп карамыйча гына әйтте. Шунда ук сизгән иде Рамазан аның алдашуын. Аннары бит Баһадурның әтисе ул көнне өстенә нәкъ бездәге кебек күлмәк-чалбар киде, галстук та бәйләп куйды әле. Анысын Рамазанның монда беркем өстендә дә күргәне юк.

Сиринә дә инде... Яшерен-батырын түгел, Рамазанның бик күрәсе килә аны үзе. Очрашырга гына курка. Булдыра алмый ул әйткән эшне малай, аның кадәр үк тәвәккәл түгел ул. Әләксәң әле тагын... Бәләкәйрәк чагында әйбер урлап тотылганы бар аның, бу хәтәр эшнең ни икәнлеген белә. Классташы Наилә белән мәктәптән кайтып килешләре иде, юктан гына бәхәсләшеп киттеләр. «Малайлар елдам булырга тиеш ул, ә син аяк өсте йоклап йөрисең,— дип үртәде аны кызый.— Әнә алып чыгып бир теге клумбадагы гөлләрне, иртәгә бит минем туган көнем»,— диде. Шунда әллә нәрсә булды Рамазанга. Тәбәнәк таш рәшәткә аша сикереп төшеп, берничә канәфер чәчәге генә өзеп өлгерде, кулыннан кемдер авырттырып эләктереп тә алды. Күтәрелеп караса, милиционер абый басып тора. Ә Наилә урамның теге башына ук барып җиткән иде инде. Шундый хурланды Рамазан, шундый хурланды, күз яшьләрен йотып, һич карышмыйча милиционер артыннан өстерәлеп китте... Шул вакыйгадан соң Наиләне уратып йөри башлады малай. Шулай да берчакны тегесе, җаен туры китереп, кабат үртәшә башлаган иде, җилпенеп килеп, бөтен классташлары алдында кар көртенә төртеп екты. Пошмас дигәч тә!.. Китте әләкләш, китте елаш. Ә башкалар хәйран калып тик карап тора. Чебен үтерергә дә жәлли торган Рамазан кызларга кул күтәрсен әле! Тик, ни гаҗәп, укытучы апасыннан тиргәү сүзе ишетмәде малай ул көнне.

Кызык, ялгызың гына калсаң, истәлекләргә бирелә башлыйсың икән ул. Чит җирдә булгангадыр инде. Уйланып йөри торгач, Рамазанның өзелеп-өзелеп өйгә кайтасы килә башлады. Әти-әнисе аның белән көрешү өметен җуйгандыр инде... Әнисе ачуланудан туктагандыр, ул да сагынадыр Рамазанны. Бер төнне ул аның төшенә керде. Ап-ак күлмәк кигән, шундый ук ак яулык ябынган иде. Ә йөзе шундый ягымлы! Рамазан янына килеп, озак итеп башыннан сыйпады. Уянып киткәч тә, күзләрен йомган килеш озак ятты малай, әнисенең сурәтен озаграк тоясы килде... Булмәсе шул килеш тора микән? Дәрес әзерли торган өстәлен, компьютерын күргәндә, әтисенең дә үзәге өзеләдер... Баһадур белән дә дуслашып өлгерде, аннан аерылу да кыен булыр инде.

Әгәр болай итсәң... Берничә елдан соң мәгарә авызында очрашырга дип, Баһадур белән сүз куешсаң... Ышанычын акламады дип әйтеп булмый бит, кабат килүенә каршы килмәс ул аның.

Йөри торгач, җәйләүгә кадәр барып җителгән икән. Рамазан, Баһадур кебек чөңгелдәп, Алтын Тамганы дәшеп алды. Бу ат үзе дә ияләшеп бетте инде малайга, тавышын ишетүгә, уйнаклый-уйнаклый килеп җитә, башын ия төшеп, өстенә атланырга булыша.

Әйдә, чап, Алтын Тамга, чап! Бәлки, Рамазан инде синең белән соңгы кабат күрешәдер. Оч, кызурак оч! Мондый рәхәтлекне Казанда елап эзләсәң дә табып булмаячак!

Җәйләү ихатасы да әллә кайда калды инде, кыя кырыендагы ныгытма челтәрләре дә яннан выжылдап кына «узып» китте. Рамазан белән бахбайның бердәм җилпенгән тавышларына якын-тирәдә кукраеп утырган бөркетләр башларын сузып-сузып карадылар. Шул кызулык белән урман эченә дә җилдереп барып керделәр. Рамазан анда да туктамады, Алтын Тамгасын әйдәкләвен белде. Артларыннан чытырманлык эчендә корыган агач ботаклары шарт та шорт сынып калды. Рамазан, исенә килеп, малкайны тынычландырырга азаплана башлады. Әмма тегесе аны тыңларлык чамадан узган иде, пошкыра-пошкыра ыргылуы булды, малай йөзе белән беләк юанлыгындагы агач кәүсәсенә килеп төртелеп, әүмәкләнә-әүмәкләнә җиргә очып төште.

Шулай күпме миңгерәп яткандыр, аңына килеп, күзен ачканда, Рамазан баш очында гына Алтын Тамганың таптанып торуын сизде. Дустының хәрәкәтләнүен күргәч, бахбай илерә-илерә кешнәп җибәрде. Аннары, гадәтенчә, ал аякларына тезләнеп, малайның өстенә атлануын көтте. Рамазанның үтереп башы сызлый иде, өстәвенә бик яман укшыта да башлады. Бераз хәл алгандай булгач, бөтен көче белән күтәрелеп, Алтын Тамга өстенә ауды.

Мәгарә хастаханәсендә Рамазанны өч көн эчендә аякка бастырдылар. Сиринә иртәле-кичле аның янында булды.

— Баш миең селкенгән, ике кабыргаң сынган иде,— дип аңлатты ул соңыннан.— Нинди сихергә ия болар,

белмим. Бездә булса, айлар буе аунар идең әле караватыңда.

Кайту юлындагы сөйләшүләре кабат теге карта тирәсенә барып ялганды.

— Ышандыңмы инде минем сүзнең дөреслегенә? — дип, кабат-кабат тукыды Сиринә.— Шушында күпме вакыт ятып, буш кул белән чыгып китүне тарих, гомумән, гафу итмәс!

Бу вакыйгага чаклы Рамазан ничек Казанга кайтып җитү турында уйланса, Сиринә һаман да шул карта күчерү хыялы белән янып йөргән икән.

— Болай итәбез,— дип, бик тәфсилләп үзенең планын аңлатып күрсәтте кыз.— Без аны миллиметрлап ятлыйбыз. Китапханәдән чыккач, кәгазьгә күчерәбез. Ул кәгазьне Зөбәрҗәт әйберләре арасында сакларммын. Алай-болай мине тикшерсәләр дә, аннан шикләнмәячәкләр. Берәр ничек җайлармын әле...

Рамазан күнде. Хәер, Сиринәнең хаклы икәнлегенә болай да төшенеп бара иде инде ул.

Китапханәгә аерым-аерым йөрергә дип сүз куештылар. Барган саен картаның берәр сантиметрын отып алырга дигән йөкләмә алдылар. Телдән генә, билгеле.

Дустының мәгарә китапханәсенә көн дә эшкә барган кебек йөрүенә гаҗәпсенгәндер инде, беркөнне Рамазанга Баһадур да иярде. Юлда барганда:

— Нинди кызык таптың соң анда? — дип йөдәтеп бетерде.

— Ярый ла, син китапханәгезнең аркылысын буйга йөреп чыккансың,— дип акланган булды Рамазан.— Андый китапларның бездә чиреге дә юк бит. Менә син Чуфут-каледа ничә шәһәр барлыгын беләсеңме?

— Ничә?

Рамазан Баһадурның бу соравын ихластан дип кабул итте:

— Йөз алтмыш җиде! Сезнекеләр, дөрестән дә, беренче булып килеп утырган. Калганнары Әхмәтханныкылардан үрчегән. Иң әүвәл Галиханныкылар аерылып чыккан. Ул — Әхмәтханның оныгының оныгы. Атасы белән сүзгә килешеп ташлап чыккан. Тик гомере кыска булган. Ата-ана каргышы дигән нәрсә бар икән ул. Шуңа күрә Галиханныкылар һаман да әллә ни алга китә алмыйлар... Кара әле, Баһадур, анда сезнең

бабаларыгызны гел әйбәт итеп кенә язмаганнар. Юкса гел «без» дә «без» дисең. Унбишенче-унҗиденче гасырларда ул мәгарәләрегез кайберәүләр өчен зиндан булып та хезмәт иткән. Кырымга солых төзергә җибәрелгән рус илчесе Айтимеров, мәсәлән, өч ел шунда ябылуда яткан. Әсирлеккә төшкән гаскәр башлыгы Шереметьев мәгарә төрмәсендә егерме бер ел утырган! Анда бай әсирләрне генә тотканнар, йолым түли ала торганнарны гына. Ярлыларын диңгез арты байларына сатканнар. Шереметьевның рус патшасының якын кешесе икәнлеген белеп, хан аның өчен безнең Казан һәм Әстерхан шәһәрләрен үзенә бирүне таләп иткән. Шереметьев андый кыйммәт бәядән үзе баш тарткан... Күрдеңме безнекеләрне! Үзенең тормышына караганда халкы, иле кадерлерәк булган аның өчен!.. Чуфут-кале турында элек тә укыганым бар иде инде, унсигезенче гасыр урталарында ул тирәдән халык китеп беткән, Бакчасарай, Симферополь, Евпатория шәһәрләренә күченгәннәр дип язганнар иде. Сез тарихны шәп алдагансыз!

Баһадур дустының дулкынлана-дулкынлана сөйләгән хикәятен көлемсери төшеп тыңлап барды. Рамазанның соңыннан гына башына барып җитте: мөгаен, ул аны сынар өчен сөйләткәндер. Китапханәдә сәгатьләр буе нишләп ятуын беләсе килгәндер. Рамазан бит дөрестән дә китаплар актарып утыра. Аның «Тарих» дигән бүлегендә берәр тапкыр «казынып» чыкмаса күңеле булмый. Ә теге тылсымлы бүлмәгә биш минутка гына сугылып чыга ул. Картаның аркылы кырыйларына бер сантиметр саен хәрефләр сугылган, буена — саннар. Шуларны күңеленнән генә үзара тоташтырып, бүген ятланырга тиешле урынны таба, берничә генә минут текәлеп карап тора да, чыгып китә. Бу юлы кереп тормаска булган иде инде, Баһадурда шик тудырырмын дип курыкты. Тик тегесенең әллә түземе шул чаклыга гына җитте, әллә, дөрестән дә, монда ул тотып карамаган китап калмаган идеме, үзе зурлыгындагы энциклопедия эченә «чумып» утырган Рамазанга карап тел шартлатып куйды да кайтырга кузгалды. Аңа дәшеп тә тормады, «китап корты» икәнлегенә бу юлы, дөрестән дә, ышанды бугай.

Рамазан белән Сиринә партизаннарча эш итте. Тора-бара бу шөгыль икесенә дә шулчаклы ошап китте,

уңышлы төгәлләнгән һәр көн күңелләренә бәйрәм рухы өсти, яшертенлек, серлелек көннәрен тагын да мәгънәлерәк итә кебек тоела башлады. Рамазан аның әле ахырын уйламый, ул әле бүгенгесе белән мәшгуль: Бакчасарай ягыннан керә торган юл авызыннан алып тегe экәмәт вагонга хәтле булган араның сурәтен төшерү. Сантиметрга сантиметр ялгап, икәүләп хәйран ара «үттеләр». Алдан килешенгәнчә, Сиринә ул кәгазь кисәген Зөбәрҗәтнең укый-укый тузып беткән, инде тотып та карамый торган китаплары арасында саклый. Рамазанның әйберләрен барлап-тикшереп йөрүче дә юк үзе, шулай да, Сиринә әйтмешли, бу «кыргый халык»ка ышаныч аз, уйламаган җирдән әллә ниләр китереп чыгарырга мөмкиннәр.

«Кыргый» дип инде... Сиринә аны ачуыннан гына шулай дип әйтә. Җирдә әкият итеп кенә сөйләнә торган нәрсәләрнең монда гадәти хәл икәнлегенә үзе дә гаҗәпләнеп туя алмый кыз. Беркөнне «Җир өсте» күленә су коенырга дип менделәр. Сиринә, ялгыш яр кырыендагы кабырчыкка басып, аягын җәрәхәтләде. Кычкырып җибәрде дә, чүгәләп, кулы белән авырткан урынына ябышкан иде, бармак араларыннан кан саркып чыкты. Кызый бөтенләй югалып калды, каушавыннан күлгә йөгереп кереп китте. Аның аяк турысында су өстенә куе кызыллык җәелде. Тик бу озакка бармады, шул урын үзеннән-үзе акрынлап зәңгәрсу төскә керә барды. Сиринә, аптырап, кабат яр кырыена чабып чыкты. Караса, җәрәхәтнең эзе дә калмаган! Бу күл суы да сихер көченә иядер, дип уйламаганнар иде әле. Баласы-чагасының, яше-картының ник шушында чупырдап ятуы аңлашыла инде болай булгач!

— Ник, хастаханәдә чирләп ятучыларның азлыгына игътибар итмәгән идеңмени теге чакны? — дип, Баһадур яткан җиреннән генә Сиринәгә шаккатып карап каткан Рамазанга дәште.— Монда табигатьтән көч алабыз, дип әйтмәгән идеммени?

Сиринә Рамазанга мәгънәле итеп карап куйды. Дөрес юлдан баруыбызга ышандыңмы инде, янәсе. Мәгарә кешеләренең берсеннән-берсе мәһабәт буй-сынлы, янып торган йөзле булулары да шуннан киләдер, мөгаен. Карт кешеләрнең берән-сәрән генә күренүе дә нәрсәнедер аңлатмый микән әле?

* * *

Вакыт бара, Әхмәтхан каласына илтә торган «юл» кыскарганнан-кыскара. Инде үзләрендә табигать көзгә авышкандыр, мәктәпләрдә укулар башлангандыр. Партадашы Искәндәр тарих укытучысы Айсылу Мәннановнаның бер дәрестә ничә тапкыр «значит» дип әйткәнен санап утырадыр. «Химичка» Динә Вәлиевна һаман да шулай акбурга буялып йөри микән? Директор Илдар Ханович коридорда чабып йөрүчеләрне кабинетына берьюлы икешәрләп, ике кулы белән колакларыннан тотып алып керә торган иде, һаман да шулай итә микән? Классларында Рамазанның урыны буштыр, әллә берәрсе күчеп утырды микән?.. Юк, кайтырга кирәк, кайтырга!

Беркөнне, Баһадурларның ишегалларында җыелышып кич утырганда, Рамазан шул хакта сүз чыгарды.

— Ник? Монда ошамый башладымыни? — дип, бәләкәй Зөбәрҗәт Сиринәнең беләкләренә килеп сарылды.

— Рәхәт тә...— Сиринә дә соңгы вакытларда моңсуланып йөри башлаган иде.— Бездә дә бит урмансулар матур, биек-биек таулар да бар... сездәге кебек үк булмаса да... Әти-әни, дуслар сагындырды...

— Мин аннары сезне күрмәммени? Кабат монда әйләнеп килмәссезмени?

— Менә сезнең үзегезне кунакка алып китәргә иде! Шушы тау тишегендә качып көн күргәнче, бергә-бергә аралашып яшәүгә ни җитә!

Монысы Баһадурга ошамады. Ул йөзен чытты да Сиринәгә яны белән борылып утырды.

— Качып, имеш. Бар, аралашып яшә сезнең халык белән! Биш тиен акча, бер адым җир өчен канга батып сугышасыз бит сез. Әхмәт бабай язмышы кабатланмас дип, кем ышандыра алсын безне? — Аннары бераз гына дәшми утырды да, Рамазанга карап:

— Теләсәң, без синең белән сүз куеша алабыз,— диде.— Вакыт билгелибез дә очрашабыз. Түлке ялгызың килсәң генә. «Койрык» ияртсәң, үзеңә үпкәлисең, бел!

Рамазанның башыннан рәхәт дулкын йөгереп узгандай булды. Үзе дә нәкъ шул турыда хыяллана түгелме соң ул? Әйтергә генә кыймый, бөтен эшне бозып куярмын дип курка иде.

Шул чакны Баһадурның карашы Сиринәнеке белән очрашты. Кызый сөенеченнән балкый иде, шул халәтен яшереп кала алмады. Баһадур аның уйларын шунда ук чамалады:

— Мин болай гына әйттем... Андый эшкә мондагылар барыбер риза булмас,— дип, урыныннан кузгалды.

...Төенчекләр төйнәлде, җандай кадерле кәгазь кисәге — мәгарә каласына илтә торган лабиринт картасы, әллә ничәгә бөкләнеп, Рамазан кроссовкасының олтан астына кереп утырды. Сиринәнең күпмедер гривналары сакланган икән, аларын да барлап куйдылар. Мәгарә авызына чаклы озатып куйсалар, калган араны ничек тә кайтып җитәрләр, шәт. Җир өстендә дә миһербанлы кешеләр юк түгел бит ул.

— Юлга чыгар алдыннан мәчеткә кереп чыгыйк,— дип тәкъдим итте Баһадур.

— Сиринәне дә дәшик, соңгы көнне генә үпкәләтмик инде,— дип, Рамазан Ибраһим абзыйларга кереп киткән иде, бик тиз әйләнеп чыкты. «Баһадурны күрәсем килеп тормый әле,— дип үҗәтләнде кызый.— Хет бер генә көн булса да ялгызым ял итеп калыйм». Рамазан боларын Баһадурга әйтеп тормады. «Арыган ул»,— дип кенә куйды.

Мәчетләре шактый еракта икән, аскы юлга төшеп, машина белән бардылар. Килеп туктауга, Рамазанның колагына моңлы азан тавышы килеп керде. Аларның Казандагы йортлары Болгар мәчетеннән ерак түгел, болай да йөрәгенә якын таныш аваз ул. Рамазанның күңелен тел белән әйтеп аңлатып булмый торган ят бер хис биләп алды. Әти-әнисен, дус-ишләрен сагынуымы бу? Туган каласына ашкынуымы? Бер үк вакытта Баһадурга, мәгарә халкына рәхмәт хисе дә, бу гаҗәеп дөньяга соклану да, аларның яшәешен аңлап җиткермәүдән гаҗизләнү дә бар иде анда. Малайның аяклары өстерәп бара алмаслык хәлгә килде, Баһадур аны мәчет капкасына җитәкләп диярлек алып барып җиткерде. Рамазан монда үзләрендәге шикелле алтын-көмеш бизәкләр төшерелгән стеналар күрермен, чәчәкле-чуклы бәрхет паласларга аяк басармын дип уйлаган иде. Әмма мондагы аклык, пакьлек, гадилек ул купшы бизәкләрдән мең тапкыр илаһирак тоелды аңа. Җанга үтеп кереп, күңелләрне айкалдыра-чай-

калдыра торган моңлы азан тавышыннан аның гәүдәсе җиңеләеп киткәндәй, башы рәхәт, йомшак томан эчендә калгандай иде. Тагын нәрсә булгандыр, калганын хәтерли алмады. Исенә килгәндә, җир өстендәге чирәмлектә, пальма күләгәсе астында ята иде. Янында, аякларын бөкләп, Баһадур утыра. Дустының күзләрен ачканын күргәч, йөзе яктырып китте:

— Куркыттың син, малай. Бигрәк озак яттың. Хәзер ничек соң? Башың авыртмыймы? Тәнең сызламыймы?

Рамазан «ә» дип тә, «җә» дип тә җавап кайтармады. Иксез-чиксез зәңгәр күккә карап, тын гына ята бирде. Рәхәт, бик рәхәт иде аңа. Бер җире авыртмый, күңелен икеле-микеле уйлар, соңгы көннәрне черкиләр кебек килеп йөдәткән эч пошыргыч тойгылар да бимазаламый. Инде аягына баскач та, тәнендәге җиңеллеккә хәйран гына исе китеп торды.

— Күңелеңнең чистаруы, сафлануы бу,— дип аңлатты Баһадур.— Өеңә кайтып җиткәч тә, элек бертөрле караган нәрсәләрне икенче төрле күрә башлаячаксың әле. Әйткән иде, диярсең менә!

Икенче көнне таң белән кузгалдылар. Вагон ихатасына кадәр аларны олысы-кечесе — монда кем таныш, һәммәсе дә озата барды. Вагонга өчәүләп керделәр. Бик ялынса да, Зөбәрҗәтне алмадылар, юл ерак, арырсың, диделәр. Башка чакта чикерткә кебек сикеренгәләп, кая барып бәреләсен дә белми торган шомырт күзле, сумаладай кап-кара озын чәчле бу сөйкемле кызчык тынып, басынкыланып калган иде. Ул Сиринә белән кочаклашып саубуллашты. Икесенең дә күзләрендә яшь иде.

Таныш юллар Рамазанга инде күптән артта калган газаплы кичерешләрен кабат искә төшерде. Караңгы тау куышында каңгырып утыру, гигант елан белән күзгә-күз очрашулар... Түш белән генә шуышып үтә торган урынга җиткәч, Баһадур башта Сиринәне уздырып җибәрде, бу якта икәүдән-икәү генә калгач, Рамазанның колагына пышылдады:

— Монда килеп адашкан көнеңне хәтерлисеңме? Һәр елны шул иртәне мин мәгарә авызына — таштан коелган бөркет сыны янына чыгармын. Кайчан да булса килергә уйласаң...

Өчәүләшеп инде шактый ара уздылар, берән-сәрән «кое» тишекләреннән төшкән яктылык та күренә башлады. Мәгарә авызына якынлашкан саен, Рамазанның күңелен кабат газаплы уйлар җәфаларга тотынды. Кроссовка олтаны астындагы кәгазь кисәге дә табанын пешерә сыман иде.

Якты дөньяга килеп чыккач, Сиринә түзмәде, шатлыгыннан «ура!» кычкырып җибәрде. Аннары, гаҗәпсенеп, тын гына атлаган Рамазанга күтәрелеп карады:

— Нәрсә сөмсерең коелды? Кайтып барабыз бит, малай, кайтып барабыз!

Еракта, үзәнлектә, нокта гына булып туристлар автобусы күренә иде. Тирәсендә кешеләр кайнаша, кайберәүләр тау битенә сибелгән, нәрсәдер җыялармы, әллә фотога төшәләрме шунда... Берара киткәч, Баһадур сукмак читендәге галәмәт зур таш кырыенда тукталып калды.

— Мин шушында торып торам. Автобус кузгалгач китәрмен. Сез миңа кул изәрсез.

«Шикләнә»,— дип уйлап куйды Рамазан. Дөрес эшли. Ул үзе дә Сиринәнең Баһадурны сатмаячагына тамчы да ышанмый.

Тыенкы гына саубуллаштылар. Баһадур таш өстенә менеп «кунаклады». Рамазан белән Сиринә алпан-тилпән автобус ягына таба тәпиләделәр. Килеп җиткәч, халык арасына кереп югалдылар. Ул да булмады, автобус шоферы озын-озын гудок бирә башлады. «Төялешергә!» дигән әмер иде бу. Безнең мосафирлар да кысылыша-кысылыша ишеккә таба елышты. Автобус җай гына кузгалып китте, арттан өермә булып тузан болыты күтәрелде... Шулчак әлеге тузан эченнән зур бер «йомгак» тәгәрәп чыкты да, җан-фәрманга кирегә — тау сукмагы буйлап Чуфут-кале мәгарәләренә таба йөгерде. Бу — Рамазан, автобус зур тизлек алырга өлгергәнче, ишеген эчтән капылт кына ачып, җиргә сикереп төшкән икән. Эчтәгеләр абайлап, автобус кирегә таба чигенә башлаганчы, Рамазан хәйран юл алып өлгергән иде инде. Баһадур турысына җитәрәк, барган уңайга гына тыйтаклап сикерә-сикерә кроссовкасын салды да аннан әллә ничәгә бөкләнгән дәфтәр битен тартып чыгарып, дустының кулына тоттырды:

— Сезнең тормышыгызга тыкшынырга хакыбыз юк

безнең, Баһадур! Бездәгегә караганда әйбәтрәк сезнең халык, чистарак, сафрак. Бик күпкә гыйлемлерәк тә. Әмма бит моңа һәркем үз көче белән ирешергә тиеш, кемнедер җәберләп түгел. Мин моның шулай икәнлеген аңлаган идем югыйсә!..— Рамазанның тамагына төер тыгылды.

Рамазан тау итәгеннән күтәрелә башлагач ук, Баһадур аңа сәерсенеп карап торган иде, эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлагач, ул әсәренгән, каушаган дустын иңеннән кочып алды:

— Рәхмәт, дустым! Мин синең шәп кеше икәнлегеңә беркайчан да шикләнмәдем! Кабат тагын очрашырбыз әле! Чуфут-кале малайлары бит без!

Автобустагылар, янәдән җиргә сибелешеп, ни дә булса аңларга тырышкан арада, иң соңгы кеше булып җиргә Сиринә сикереп төште. Автобус тәрәзәсе аша ул Рамазанның кроссовкасын салуын да, Баһадурга кәгазь кисәген тоттыруын да күреп торды. Иреннәре кысылган, яшькелт күзләрендә зәһәр очкыннар биешә иде кызның. Кемне-кемне, ә менә аны — яшьтәшләреннән утлыгы белән дә, мутлыгы белән дә аерылып торган чая Самара кызын төп башына утыртсыннар әле! Алдына китереп куймасаң, сорап алып ашый да белмәгән Казан мокыты шундый нәрсәгә барыр дип кем уйлаган! Чыгып киткәндә Сиринәне бит берәү дә килеп тентемәде, никләр генә картаны Рамазан кулына тапшырды соң ул?!

Ул арада Рамазан, кәҗә шикелле сикергәли-сикергәли, автобуска якынлашты, Баһадур исә аның ягына соңгы тапкыр карап алды да мәгарә авызына кереп югалды...

# Мәмдәлләрдә генә утлар яна



*Өлкән буын кешеләренә көнләшеп карарлык. Тырышканнар, тырмашканнар алар, каһәрләнгәннәр, рәнҗетелгәннәр, әмма иманнарын җуймаганнар, кыйблаларыннан язмаганнар. Ниләр генә күрсәләр дә, тормыштан суынмаганнар, якты киләчәккә өметләрен өзмәгәннәр. Мөгаен, нәкъ менә шуның белән дә бәхетле булганнардыр алар. Без мондый бәхетне алар аңлаганча беркайчан да кабул итә алмабыздыр.*

*Минем әтием Нәгыйм Сабиров унөч яшеннән авыл укытучысы булып эшли башлаган, Ватан сугышында булып, исән кайткан, калган бөтен гомере буе шунда алган яраларыннан сызланып яшәде. Кырык җиде ел педагогик стаж белән пенсиягә чыкты, аннан соң да һәр мизгелнең кадерен белеп яшәде, туктаусыз хәрәкәттә иде. Мин аның язмышыннан зарланганын, сукранганын, тормышны каһәрләгәнен ишеткәнем булмады. Бүгенге болгавыр заманны, гомерләре буе ашкынып якынайтырга тырышкан якты киләчәккә булган өметләренең челпәрәмә килүен күрә алмады — кем белә, бәлки, нәкъ менә шуның белән дә бәхетле булгандыр ул.*

*Бу хатирә — әтиемнең дөньяны танып белә башлаганнан алып вафатына кадәр тормышын эченә алган көндәлек дәфтәрләренең бер кисәге. Илебезнең алты дистәдән артык тарихының чагылышы да анда, шул вакыйгаларның эчендә кайнаган авыл зыялысының аларга мөнәсәбәте дә. Бүгенге укучы өчен ул чор кешеләренең фикерләве, тормышка карашы сәеррәк булып тоелырга да мөмкин. Әмма шул инану, ихластан ышану яшәткән дә инде аларны.*

*Әтием исеменнән бәян ителгән әлеге көндәлекләрдә өлкән буын кешеләренең үз язмышларын яисә якыннарының тормышын тоемлавында шигем юк.*

**1914 ел.** Җир йөзен, өлгереп җиткән иген басуларын кояш кызуы көйдерә, кешеләрне хәсрәт уты яндыра. Тормыш чыгырыннан чыкты, күңелләрне өметсезлек, караңгылык каплады.

Ул көнне без дә гаиләбез белән уракта идек, сугыш башлану хәбәрен шунда ишеттек. Әтиемә, запастагы солдат булганлыктан, шул көнне үк чыгып китәргә кирәк иде. Елаш, аһ-зар! Өлкәннәр — улларын, бала-чага атасын, абзасын озата. Муллалар да, мәчет картлары да килгән, алар сугышка китүчеләрне үзләренчә юаталар, үгетлиләр: «Газиз Ватаныбызны, падишаһ әгъзам хәзрәтләрен сакларга барасыз»,— диләр.

Мин ул чакта сугышны нәрсә дип тә күз алдына китерә алмый идем. Кем белән кем сугыша? Кул белән суккалашалармы? Таяк белән үк сибешәләрме? Нинди кеше икән ул Герман? Кыска булса, безнең әти озын аяклары белән тибеп кенә очырачак аны!

Халыкның аһ-зары бәләкәй йөрәгемдә мәңге онытылмаслык булып уелып калган. Ул хәтеремә әтиемнән аерылып калу белән беркетелгән. Ятим калуымның тәүге минутлары белән...

Авылда ирләр аз калды, калганнарының да эшкә булган дәрте сүнде. Көзгә каршы явымнар башланып китте, бик яхшы уңган игеннең күп өлеше яңгыр астында череп, харап булып бетте. Ил өстендәге хәсрәт сөреме көз караңгылыгы белән кушылып, киләчәкне өметсезләндерә, йөрәкләргә авыр шом сала иде. Суык килә, яңгыр ява, җил исә, менә инде кар да оча. Сугыш бара...

Шул рәвешчә, ундүртенче елгы сугыш әнине өч бала белән тол калдырды, безне (миңа — өлкән балага — алты яшь) үксез итте.

Кышны үз йортыбызда үткәрергә булсак та, язмыш үзенекен итте. Унбишенче елга кергәндә, әни икенче энем Гыйльмеханны тапты. Үзе тиф белән авырый башлады. Дәү әти йортына күчеп төшәргә мәҗбүр булдык. Әнинең Шәяхмәт абыйсы гаиләсе белән дәү әти ишегалдындагы йортта яши иде. Мин Нургаяз энем белән шуларда торырга тиеш булдым. Әни дәү әтинең ак өендә авырып ята, яшь бала әни янында. Ул аны үзе карый алмый, башкалар баланы кагалар, тизрәк үлүен телиләр...

Ул чакта дәү әти сәүдәгәрлек итә иде, авылда аның «двор өе» һәм урта өенә терәтеп салынган кибете бар иде. Тормышлары мулдан булса да, безгә — оныкларына ачык чырай күрсәтмәде. Өстәвенә Шәяхмәт абый-

ларның шау-шулы тормышларының тәртибен дә белми идек.

Тамак тәмугка кертә, диләр. Без дә Нургаяз энем белән хәтәр эшкә күнегеп киттек: урта өй аркылы дәү әни янына барабыз. Беребез шунда качып кала, икенчебез, ак өйгә кереп, дәү энидән сату өчен әһәмияте беткән клиндер ватыклары сорый. Ул кибеткә кереп чыга да, озатып, урта өй ишеген эчтән бикләп куя, үзе ак өйгә кереп китә. Шунда урта өйдә качып калганыбыз, кибеткә кереп, хәлвә, йөзем җимеше, прәннек ише нәрсәләр төйнәп чыга...

Уналтынчы елның көзендә сабак укый башладым — иске киез катаны сөйрәп, Нурмөхәммәт мулла өенә йөрим. Киез итегем кипми, мич башына куйсам да, Шәяхмәт абыйның кызлары аннан алып ыргыталар. Юеш итекләр суыкка чыккач шыкырдап ката, таеп китәм дә, лапылдап барып төшәм. Аякларым туңа, сызлый. Нургаязның исә аягына бөтенләй юк, урам чыраен күрми өйдә утыра, мескенем.

Озакламый дәү әти безне дә башка чыгарды: без яши торган өен икенче урамга күчереп салдырды. Абзар сыман нәрсә дә ясатты. Капка-койма булмаса да, үз йортыбыз бар, дип әйтерлек хәзер. Атыбыз юклыктан, авыл хуҗалыгы эшләрен дәү әти белән бергә алып барырга мәҗбүр идек. Ашарыбызга да дәү әти нормалап — паеклап кына биреп тора. Әмма аның да безнең кулга керү юлы бик катлаулы. Чөнки без хәзер паразит дип исәпләнәбез. Ашарыбызга бетеп, сорап барырга туры килсә:

— Әле бетте дәмени, бирәннәр! — дип кычкыралар...

Шау-шулы заманнар... Дөнья актарыла, Рәсәй казан кайнагандай кайный. Унсигезенче елның август башында Казанга аклар бандасы — чехлар керүе хакында хәбәр килеп җитте. Кызыл гаскәрнең чигенеп баручы бер кечкенә төркеме безнең Мәмдәлгә килеп керде. Авылның кансыз, таш йөрәкле бандитлары шатлыктан шашындылар. Кызылларның кайсын талап, кайсын үтереп йөрделәр. Ай ярым вакыт үтте микән, Мәмдәлгә кызыл җәза отряды килде, теге бандитларны тотып, берәм-берәм атып үтерделәр...

Шушы канлы вакыйгалардан соң авыл халкы төрле катламнарга бүлгәләнә башлады. Кемнәрдер Совет-

ларга дошман караштa тора, кемнәрдер кызылларны хуплый, өченче берәүләр (болары күпчелек) уң белән сулны аера алмый буталып интегәләр иде...

Шушы елның уналтынчы октябрендә Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитетының «Берләштерелгән хезмәт мәктәбе» турындагы положениесе игълан ителде. Авылда мәктәп ачылганда, кыш җиткән иде инде. Аны «Эш мәктәбе» дип аңлаттылар. Иркенләп укый-яза алганлыгымнан, мөгаллим Габделхәй абый мине икенче сыйныфка язып куйды. Бер атна укыдыммы, юкмы, өченче сыйныфка ук күчерделәр. Фән предметлары арасында безгә көнгә бер сәгать дин дәресе дә бирәләр иде. Шулай булмаса, халык борчылачак иде.

Караңгы татар авылында туып үсеп килә торган яшь буын өчен бу мәктәп бер могҗиза булды. Безгә, дин китапларыннан башкасын күрмәгән малайларга, дөнья белеменең исе хәйран керде. Минем иң мавыкканым арифметика булды. Җәгъърафияне аңлыйм. Харита (карта) өстендә яхшы йөрим. Шигырь дигән нәрсә дә бар икән ләбаса. Коръәнне тәҗвид белән укыйбыз. Аятьләр ятлыйбыз.

**1919 ел.** Мин — йортыбызның төп хуҗасы. Унбер яшь тулып китте бит инде. Җәен хуҗалыкны үзем алып барам. Җир сукаларга чыгу өчен, иртүк торып, дәү этиләргә менеп китәм. Күп очракта әни мине ашатмый гына чыгарып җибәрә. Дәү этиләрдә тамагы үтәр дип өметләнә. Әмма анда иртәнге чәй миңа бик эләкми. Эләккәндә дә табындагы икмәкне җир сукаларлык итеп тешләп булмый.

Менә бүген дә йокыдан уяна алмый җәфаланам. Көндез кырда ачлы-туклы эшләп йөреп арыган, талчыккан гәүдәм, эреп, камыр кебек таралып ята. Арбада утырып барам, имеш, үзем тыныч, ә аягым селкенә. Уяна башлыйм да, тагын саташа-саташа йоклап китәм. Ниһаять, айныдым. Янымда әни басып тора икән, аягымны йомшак кына итеп ул селкетә. Көтү куарга җыенган, мине уятып калдыруы.

Матур май иртәсе, кояш күтәрелеп килә, өй эче яп-якты. Минем янымда, сәкедә, аяк-кулларын як-якка ташлап, үтә татлы бер тәм белән энеләрем йоклап ята. Нургаяз куенына кереп бөгәрләнгән песиебезнең генә тәмләп мырылдавы ишетелә. Оекбашларым, чабата-

ларым кичә кич салып калдырган урыннарында моңаешып мине көтеп утыралар иде. Башымда — әлү кагына охшаган иске кәләпүш, өстемдә — киндер күлмәк, ыштаным тагын да тупасрак киндердән булса да, тәнемә ябышып тора.

Киендем. Ишегалдына чыгып, яшел чирәмгә бастым. Җәй дисәң дә җәй! Иртәнге саф һава бөтен гәүдәне гаҗәп бер дулкын эчендә калдырып сыйпый. Шул рәхәтлек әллә нинди зур эшләргә ашкындыра, әмма бер усал көч итәгемнән тоткан, җибәрми... Их, таза киенеп, тамагың тук булып, үз ат-туның белән, үз әтиең җитәкчелегендә йөрсәң иде аны!

Капкадан чыгып, уңга борылуга, тыкрык башланып китә. Шуның буйлап югарыга таба атлыйм, дәү әтиләргә йөз тотам. Баш аңкы-миңке, гәүдә авыр. Бөтен тәнем үз алдына салынып тора, аякларым таш такканнар төсле. Иртә белән ашыйсы килми, диләр, кая ул килмәгән, бербөтен икмәкне кабып кына йотар идем әле. Һай, йокы да бик тәмле шул. Шунда сукмак буендагы кычыткан төбенә булса да ятып чымырдап китәсе иде, их!..

Дәү әтиләр иртәнге чәйне эчеп бетереп, аш өстәлен җыештырып та куйганнар иде инде. Ашау өйдә дә юк, монда да насыйп булмады. Кичә дә ач карынга ятып йоклаган идем.

Дәү әти — ябык чытык йөзле, кәҗә сакаллы, аякларына читек өстенә чабата кигән кечкенә генә гәүдәле карт — гадәтенчә, сукранып, ишегалдында кайнаша иде. Минем ялгышларыма исе китмәгән шикелле, җылылык та күрсәтми, «улым» дип дәшкәнен ишеткәнем булмады, исемемне дә сирәк әйтә, анда да «Нәгыймҗан» дип түгел, бозып, «Наемҗан» дип атый.

Башта икәү балта кайрадык. Аннары арба төзәттек, күчәр-тәгәрмәчләрне майладык. Без кайнашкан арада, күк йөзенә көнбатыштан килеп чыккан төтен сыман болыт җәелә башлады. Дәү әти сизми калды, мин өйгә элдерттем. Явым-төшем булса, өскә берәр кием алырга иде исәбем.

Ишек эчтән бикле, пәрдәләр төшерелгән, әни, көтүен куып кайткан да йоклап киткән.

Ул чакта елның бу вакытында татар хатын-кызларының әллә ни эшләре юк иде. Урыс авылларында

гына ул, хатыннар көтү куганчы ук бакчаларында кайнаша башлыйлар. Ә татар хатыны яшелчә үстереп мәшәкатьләнми, көтүен куып кайта да, ак беләгенә башын куеп, кабат йоклап китә. Мари басуларына карасаң да, ирләр арасында тигез санда хатын-кызлар болында да печән чаба...

Өйалды ишегенең келәсен, бавыннан тартып, акрын гына чакылдаттым. Әни уянуын тиз уянды, әмма ишек ачарга сукранып кына чыкты:

— Әле генә яткан идем, кинәт уяндым, уф, башыма капты,— диде.

Мин, сәләмә бишмәтемне тиз генә җилфердәтеп алып чыгып, дәү этиләргә элдерттем.

Кичә караңгыга чаклы җәфаланып та, сөреп бетерә алмый калган җиребез бар иде. Туры шунда килдек. Атларны арбадан тугарып алып, сабанга җиктек. Калдык җир генә булганга, бу эшебез әллә ни озакка сузылмады. Эше бетеп торсын дип, сабанны көчәнә-көчәнә (беребез — карт, беребез — малай) күтәреп, арбага салдык. Атларны тырмага җиктек. Мин пар ат белән өч-дүрт кат әйләнгәнче, дәү эти карап, күзәтеп торды. Тырмаларга оста идем, бу юлы да сынатмадым, җиренә җиткереп эшләдем. Дәү эти эшемне ошатты гына түгел, сокланды да бугай. Дөрес, ул моны беркайчан да сүз белән белдерми, әмма мин аның гадәтен өйрәнеп бетергәнмен инде. Туктагач, арбадагы төенчеккә төртеп күрсәтте:

— Менә, ашыйсың килсә, капкаларсың,— диде.

Килмәгән кая ул! Авызга соңгы мәртәбә ризык кергәнгә нәкъ бер тәүлек була бит инде. Икмәк кыерчыгына ике куллап тотынганда, күз алларым тәмам караңгыланган иде.

Дәү эти, ике кулын артка куйды да, акрын гына атлап, су тегермененә таба китеп югалды. Мин дә, аякларымны һәйбәтләп сузып, ызанга утырдым. Эскәтерне җиргә җәеп салып, икмәк кыерчыгын суыра-суыра чәйнәп ашадым. Тамак туймаса да, хәл керде. Күз алларым яктырып, күңелләрем күтәрелеп китте. Эшкә тотындым. «Алмагачы» көенә җырлап та җибәрдем:

Карлыгач кара була, муены ала була,
Атадан яшь калган бала бәхетсез бала була...

Аннары: «Ничава, бәхетсез булмабыз әле!» — дип җилпенеп тә куйдым.

Озакламый вак яңгыр сибәли башлады. Ул арада дәү әти дә күренде, янында башка чыккан улы Шәяхмәт абзый да бар иде. Акрын гына атлап, сөйләшә-сөйләшә киләләр. Алма агачыннан ерак төшми, диләр. Шәяхмәт абый да дөнья куу ягыннан дәү әтигә охшаган. Сәүдә белән, төрлечә алыш-биреш эше белән көн күрә торган хәлле кеше.

Мин, атларым белән кайнашкан килеш, аларга карап:

— Абый, исәнме! — дип кычкырдым. Ул, минем сәламемне алып, елмаеп, озаклап карап торды. Мине кызгандымы, эшкә яравыма сокландымы, әтием турында уйландымы, үз кызларының бәхетен минеке белән чагыштырдымы? Аның карашы мине үртәп, елатырга тырышкан кебек тоелды. Юк, еламадым!

Яңгыр яхшы ук көчәйде. Җилли дә башлады. Дәү әти белән абый арба өстенә брезент капладылар. Арба астына атлардан калган печәнне түшәделәр дә шунда кереп чумдылар. Башларын калкытып, мин эшләгәнне күзәтеп яталар.

Тәки тырмалап бетердем. Кайтканда мин бөтенләй су эчендә идем. Ару, ачыгу, туңу тәмам үзәккә төште. Ничек кайтып җиткәнмендер, бөтен тәнем уттай кызып сәке өстендә ятканда, күз яше аралаш тирән уйларга — өметсезлекнең төпсез чоңгылына чумып, бу газаплы тормыштан котылу юлларын эзләдем. Әмма таба алмадым. Китеп кая барыйм? Өстәвенә әнине, энеләремне калдырып, ничек чыгып качыйм? Ул чагында минем урынымны Нургаяз алачак, ул тагын да баларак бит әле. Ул да шулай яшенә тыгылып: «Абый ташлап качты шул»,— диячәк.

Мин — гаилә өчен җаваплы кеше, шулай булгач, һәммәсенә түзәргә кирәк иде.

Саташулы уйлар төшемә ялганып китте. Әнинең йомшак кына аягымны селкетүенә уянып киттем. Көн туган, кабат эш иртәсе башланган икән...



* * *

Кышын мәктәптә укып йөргән булдым. Әмма бу уку мине канәгатьләндерми, программалар артык гади, барысын да укытучы аңлатканчы белеп барам. Рус телен бөтенләй өйрәтмиләр. Уку белән кызыксынуым бик көчле, бигрәк тә математиканың тәмен белеп алдым. Гади вакланманы бүлү-тапкырлау бәхете миңа юлдан табылды. Берәр сәүдәгәрнең товар төреп сату өчен әзерләнгән кәгазедер инде ул, төшеп калган, күрәсең, урамда җил белән очып йөри. Табылдыгым хисап китабының берничә бите булып чыкты. Шатлыгым эчемә сыймады.

Белемне үз ихтыярым белән эскәкләп чүпләдем. Нәрсәгәдер кирәк булыр, дигән уй башыма сеңәрлек дәрәҗәдә түгел идем. Күңел эзләнә, дөньяда тагын нинди гыйлемлекләр бар икәнлеген беләсе килү тынгы бирми. Әмма өйрәтүчем дә, киңәш бирүчем дә юк...

Адәм баласы көчле, табигатьне үзгәртә ала, җәмгыятьне дә сүтеп яңадан ясый, әмма дөнья, табигать, диалектика, язмыш ничек тә үзенекен эшли.

* * *

**1921** елның җәе бөтен өметләрне сүтеп ташлады. Кар сулары һәм язгы ләйсәннәрдән соң бөтен җәй буена бер тамчы яңгыр таммады. Яшеллек тернәкләнә алмады, күтәрелә башлау белән көйде, корыды. Кырда кереш ашы пешереп, узган-барганнарны салкын су белән коендырып йөрүләрнең дә, төрле ырымнар белән юрауларның да, хәзрәтләр җитәкчелегендә кырда намаз укуларның да файдасы булмады. Ачлык килеп басты, хәл кот очарлык иде. Халык алдында, авызын зур ачып, ерткыч тешләрен ырҗайтып, тырнакларын батырырга әзерләнеп, рәхимсез әҗәл үзе басып тора... Шундый заман килде: берәүләр ачтан үлә, икенчеләр урлап карый, тотыла, аны кыйнап үтерәләр; үз авылдашлары, үз милләттәшләре, мөселманнар үтерә. Өченчеләр, халыкның ачлыгыннан файдаланып, баеп калырга тырыша. Махсус әзерлекле жуликлар пәйда булды...

Шулай да ачлыкның иң яманы икенче җәйгә чыккач — яңа икмәк көткән чагында булды. Явым-тө-

шем күп булганлыктан, шобагасына биш пот урынына бер генә пот чәчелгән җирләребездә иген котырып уңды. Арышның өлгереп җиткәнен дә көтеп бетерә алмадык. Бер пот көлтә урып алып, кояшта киптереп алып суктык. Аны кул арбасына салып, су тегермәненә тартып төштем. Чират зур, халык күп, һәркемдә бер хәл бит. Ниһаять, ике пот арышымны онга әйләндерү бәхетенә ирештем. Ул ике пот онны сөяп куйгандай текә таудан тартып менәсе бар иде. Хәлем юк, ачмын. Өстәвенә йокламыйча чират саклаган бит әле. Арбаны таугa каршы өстерим, ә он капчыклары мине аска тартып төшерә...

Ул көнне өй эче барыбер яңа арыш икмәге исе белән тулды. Шул рәвешле, бәхетле көнгә үлмичә килеп җиттек.

* * *

Быел **(1922)** үз игенебезне дәү әтидән аерым иктек. Көзне ярыйсы гына мул каршыладык. Тамак тук булгач, миндә янә уку дәрте кабынып, дөрләп китте. Әмма кая барасың? Авылда башлангыч мәктәп кенә, анда җитәрлек утырдым инде. Читкә китәргә чама юк. Акча кирәк, акча табарлык һөнәрем юк. Кемгәдер ялланып, хезмәт хакы алырлык чамам юк. Шулай да бер нәрсә уйлап таптым: кырда игене җыеп алынган җирләрдән башак җыям. Сатарлык арышым булды. Әни белән киңәшкәннән соң, күрше Яңавылга барып укырга ниятләдем. Анда да башлангыч мәктәп, әмма укытучысы бик галим кеше икән, урысчага да әйбәт өйрәтә, ди. Миңа нәкъ менә шунысы кирәк тә.

Уку тиз башланмады, көзне үз ирегемдә үткәрдем. Каралтыга терәп төз лапас ясадым, чабата тукыдым, уйнадым, таба алганда, китап укыдым. Төнлә уянып, йоклый алмыйча, төрле уйларга чумып яткан чакларым күп булды. «Педагогик эшчәнлегем»не башлап җибәрдем: энеләремне укытам. Дин дәресләре бирәм, ана телендә укырга-язарга өйрәтәм. Әмма алар минем өчен дип кенә укыйлар, уенга чыгып таярга гына торалар.

Яңавылга да уку беткәнче йөри алмадым. Әни алып кайтып китте.

— Үлсәк, бергә үләрбез,— диде.

Коточкыч хәбәр таралган: күктән иксез-чиксез зурлыкта койрыклы йолдыз төшеп килә, ди. Бөтен

дөнья берьюлы һәлак булачак икән. Әни ышангач, мин дә аның дөреслегенә шикләнмәдем. Шунысына гына акылым җитмәде: аерым үлсәң ни дә, бергә үлсәң ни?

Хикмәти Хода, ул койрыклы йолдыз төшмәде тагын, һәлакәт булмыйча калды. (Бу хәбәр соңга калып таралган булса кирәк. Егерме икенче елда комета күренгән бит. Беркатлы халык аның турындагы хәбәрне шул комета узып киткәч тә таратуын дәвам иткән булса кирәк.)

* * *

**1923** елның көзендә авыл мәктәбенә договор белән ялланып укытырга кеше кирәк булды. Шундый «гыйлемле» һәм төрле шартларга җиңел күнә торган кеше табылмагач, авыл башлыклары миңа тәкъдим ясадылар. Хәйран калам: ни уйлап риза булдым икән мин? Акчасыннан да бигрәк, эше кадерле иде шул: халык арасында булам, кирәкле кеше булам, дип күндем. Өмет белән дәртләнеп әзерләндем.

Шулай итеп, мөгаллим булдым. Укытам. Рәтен белеп эшләвем түгел, әлбәттә. Нәрсә ул программа, план — берсен дә белмим. Предметларның дәрес саны хакында да берәүнең дә аңлатканы юк, әмма укытам. Үземчә балаларны сыйныфларга да бүлеп куйдым. Унбиш яшь тулмаган үсмер идем әле ул вакытта, шулай да үзем белгәннең күп өлешен укучыларга бирә алдым шикелле. Бала баланы яхшы аңлый. Мин бу «ачышым»нан, педагог булып үсә барган саен, киңрәк файдалана башладым: дәрес материалын балаларга үзләре аркылы бирәм. Мәсәлән, булачак дәрес материалын үзләре әзерлиләр, класста үзләре сөйлиләр, миңа төзәтергә, тулыландырырга, шомартырга, кабатлап ныгытырга гына кала.

Укучыларымның күбесе үземнән бер-ике яшькә генә кече, араларында хәтта яшьтәшләрем дә бар иде. Бер үк мәктәптә төшкә кадәр мин фән дәресләре укытам, төштән соң ишан мөрите дин сабагы бирә иде. Анысын әтиәниләре мәҗбүр иткәнгә тыңлыйлар, ә минем сабаклар балаларның үзләре өчен кызыклы. Күпчелек минем якта. Әмма ишан мөрите Гәрәй абзый бит сыпырып садака җыя, мин исә бер тиенсезгә селкенеп йөрим. Договор дигән нәрсәнең көче юк, ата-ана акча бирми.

Гәрәй абзый дөньяны кочаклап алган кеше. Хәл-

фәлек итсә дә, күп вакытта өйдә булмый. Андый чакларда аның урынына үзем керәм. Дин белеме ягыннан куркыныч юк, мин аны Гәрәйнең үзеннән шәбрәк беләм. Моны балаларның үзләренә дә ачык итеп сиздереп куям. Бу инде: «Атна кич Гәрәй абзыйга бирә торган садака акчагызны миңа тамызсагыз да ярый»,— дигән сүз. Чынлап та, бер-ике очракта шулай җыйдым. Әмма бервакыт үз дәресемдә Тукайның «Авыл мәдрәсәсе»н («Мәдрәсә дип, нәрсәдер асрый агайлар җилкәсе...») укып, «садака эше»н боздым. Хәер, минем хәйләне Гәрәй абзый болай да сизгән иде инде: садака көнен ташлап, беркая да китми башлады.

Тиешле хезмәт хакымны башкача тәки ала алмадым. Болай булмас, ахры, дип, теләнче кебек булса да, договор акчамны җыярга чыктым. Бераз булды булуын, тик бик аз шул. Аннары алай соранып йөрүемне дә ташладым. Беришләреннән тормыш хәленә кереп үзем алмадым, икенчеләре, төрле сылтаулар табып, үзләре бирмәде. Кара фикерле Шәрифә Таҗие, ишегалларына килеп кергәч, каршыма үзе чыкты. Сәламемне дә алмыйча, мыскыллы елмайды:

— Син сәвит сабагы укытып йөрдең, акчасын да сәвиттән сора,— диде. Төкердем дә чыгып киттем. Башкаларга кереп тә тормадым. Өйгә кайттым да акча җыю өчен төзелгән исемлекне, ерткалап, учакка аттым.

...Мин үземне кар-буран эчендә адашып калган мосафир кебек хис итәм. Максатым ачык — укымышлы кеше буласым килә. Әмма юлдашым, киңәшчем юк, юл күрсәтүче маягым юк. Укый торган урын бардыр ул, тик хәерче килеш сәләмәләремне җилфердәтеп кая барыйм?

* * *

**1925** елның җәендә авылда китапханә ачу минем өчен бик сөенечле вакыйга булып истә калган. Буш вакыт килеп чыгу белән шунда чабам. Китапханә хуҗасы Фатыйма апа китапларны өйгә дә биреп җибәрә. Ул үзе авылда комсомол ячейкасы секретаре хезмәтен дә алып бара иде. Бервакыт Фатыйма апа мине комсомолга керергә үгетли башлады. Мин күндем. Бик матур иде шул ул Фатыйма апа.

Шулай итеп, ике дөнья эчендә бутала башладым. Комсомол җыелышларында катнашам, дингә каршы докладлар тыңлыйм. Үзем җомга намазын да калдырмыйм. Әнине рәнҗетәсе, елатасы килми бит.

Ул җәйне минем өчен тагын бер зур вакыйга булды: кем инициативасы белән булгандыр, Арчага укытучыларның җәйге курсларына укырга җибәрделәр. Әнине ничек күндергәнмендер, ниләр әйтеп көйләгәнмендер, әмма мин бу вакыйганы зур шатлык белән кабул иттем. Тик өйдән чыгып китү шартлары коточкыч иде: печән чабып җыярга кайтып җитәргә тиешмен; киемсалым, урын-җир, ашау-эчү сорамыйм. Баласының яшьлек ярсуына гаҗәпләнеп, әни: «Ике ай буе ничек яшәрсең икән соң син?» — дип тә сорый алмады.

Укулар тоткарлыксыз башланып китте. Ит күрмәгән бичарага үпкә-бавыр да тансык дигәндәй, миңа монда бар да гаҗәп, бар да кызык. Әмма мин ач! Юлда килгәндә үк ач идем, курслар башланып, ашханәдә ашый башлаганчы монда да авызыма ризык кергәне булмады. Ашханәдә унбиш көн саен исәп-хисап ясыйлар. Шуннан файдаланып, мин бер унбиш көннең туенуын акчалата алдым — кайтырга юлга акча кирәк иде. Шул унбиш көн дәвамында көнгә ярты кадак икмәк ашап, су эчеп яшәдем. Өстәвенә алыштырырга күлмәгем, каралганын юарга сабыным юк. Иртән халык йокыдан уянганчы (без Арча мәктәбенең классларында урнашып яшәдек), мичләрдән көл дә эзләп карадым. Юк. Иске сандалиларым да тәмам эштән чыкты. Базар мәйданыннан, эзләнеп, җеп, тимерчыбык кисәкләре табып, тегештереп куйдым. Чәчем котырып үсте, чәчтарашка барырга акчам юк...

Курсларны, ниһаять, тәмамлап, авылга кайту юлым да истә калырлык булды. Казанга төнлә килеп төштем. Кая да булса фатирга керергә кыяфәтем юк иде, вокзалда калдым. Әмма вокзал хуҗалары — ватандашларым — мине урамга куып чыгардылар. Кешелекле булырга өйрәтмәгәннәрдер шул аларны. Кем белә, Ленинны да укымаганнардыр әле. Вокзал эчендә кешеләр күп калды, бары тик мине һәм агач аяклы бер теләнчене генә куып чыгардылар.

Вокзал каршысындагы эскәмиядә төн уздырырга булдым. Кечкенә мендәр белән тастымал хәтле генә

киез салынган капчыгымны яныма куйдым. Ничек йоклап киткәнемне белмим. Уянып киткәндә, кояш шактый күтәрелгән, урамда хәрәкәт башланган иде инде. Әйләнә-тирәмдә йон-мамык оча. Капчыгым ярылган, аңа, күрәсең, пычак тыгып чыгарганнар. Мендәр йоны бөтен тирә-юнемне тутырган.

...Ул җәйне күргән газапларым бушка китмәде — көзен мине авылда штатный укытучы итеп билгеләделәр. Тормыш рәтләнеп китте. Уңыш та яхшы булгач, тамак та тугая, өс-баш та бөтәя төште. Күңел күтәренкеләнде.

Әмма монда минем дус-иш юк. Тол хатын малаеның, йолкыш-хәерченең кемгә кирәге булсын! Хәзер исә авылның бердәнбер интеллигент кисәге, гүя яттчит кеше, өстәвенә — комсомол...

Беркөн шулай, әни өйдә авырып ятканда, безгә берәү килеп керде: башында фуражка, аякларында итекләр, өстендә шинель.

— Комсомол ячейкасының эшләре синдә икән,— диде.

«Миндә» дисәм, моны авыру әни ишетеп, «диннән язгансың икән» дип ачуланачак.

— Юк, миндә түгел,— дип ялганладым.

Бу кеше булачак волком секретаре Солтан Игъламов булып чыкты. Мин аңа соңыннан хәлне аңлатып бирдем. Ул бу мәсьәләне партиянең волость комитеты алдына куйган. Утырыш барышында волком секретаре тәмам чыгырыннан чыкты, мине котырып-котырып сүкте, нәсел-нәсәбемне дә искә төшерде. Мәгариф бүлеге мөдире коммунист Зәйнәп апа Мостафина тизрәк белдерү белән чыгарга ашыкты: мине укытучы итеп тотмаячак. Тавышка куелды: мин «очтым».

Ишкәкләре сынып, җилкәннәре давылга очып, су уртасында калган көймәче кебек, тормыш диңгезе уртасында утырып калдым. Хәзер минем хезмәт хакы килә торган эшем юк.

Әмма бу вакытлы халәт кенә булды. Волкомдагы иптәшләр әллә җәза кисскенрәк бирелде дип уйладылар, әллә мине алыштырырга кеше табылмады — күрше Олы Кавал авылына кабат укытучы итеп дәштеләр.

Минем янга икенче укытучы булып Лотфи Насыйбуллин дигән егет килде. Минем белән чагыштырган-

да аның тышкы кыяфәте үк «фәләнчә» иде: кирәге булмаса да күзлектән йөри, үзен бик өстен куеп сөйләшә, бик белемле булып кыланырга ярата. Бервакыт истә калырлык вакыйга булып алды. Авылга агроном килде. Рус кешесе. Актив җыелышы ясадык. Агроном авыл хуҗалыгы темасына доклад укыды. Халыкның күпчелеге русча аңламый иде, татарчага тәрҗемә итәргә кирәк булды. Шунда вәкарь белән генә Лотфулла чыгып басты:

— Үзем тәрҗемә итәрмен,— дип белдерде. Мин хәйран калдым. Чөнки зур эш. Русча белү генә дә җитми, авыл хуҗалыгын фән буларак аңларга кирәк.

Лотфи «тәрҗемә итә» башлады. Сүтә, малай, ялганлап. Агроном сөйләгәннәрне бөтенләй әйтми, үзе ясап сөйли.

Герман сугышында бер кулы өзелгән Заһир абый почмакта елмаеп кына утырып тора иде. Лотфиның кыланышы чамадан аша башлагач, түзмәде, кайры тунының кулсыз җиңен биленә шап итеп сукты да, берәүдән дә рөхсәт-фәлән сорап тормыйча, урыныннан сикереп торды:

— Ю-ук, Лотфулла нәнә, алай дими ул,— дип, агрономның сүзләрен халыкка аңлатып бирә башлады.

Лотфиның болай да кызыл йөзе ахакка әйләнде.

* * *

**1926 ел.** Авылның избачы Хәйрулла Вәлиуллин белән активлашып киттек. Булдыра алганча кичәләр үткәрәбез, докладлар әзерлибез, яшьләрне туплап, спектакльләр куябыз. Хәйрулланың тырышлыгы белән радиоалгыч алуга ирештек. Күмәкләшеп радио тыңлыйбыз. Әмма авыл халкы тавышның Казаннан ук килгәненә ышанмый. «Килер бер көн,— дим мин,— ерактан сөйләүченең тавышын ишетү генә түгел, үзен дә күрә башларбыз». Бу сүзгә берәү дә ышанмый, мыскыллы көләләр генә.

Без мондый нәрсә уйлап таптык: авыл егете Шакир абый Зариповны Казанга, радиостудиягә барырга үгетләдек.

Кичен кабат уку өенә җыйналдык. Хәйрулла радиоалгычны көйләп куйды. Халык шыгрым тулы булса

да, шул тикле тынлык, кырмыска кыштырдаганы да ишетелер иде.

— Тыңлагыз, Казан сөйли...

Халык «әһ» итеп куйды. Радио Арча кантоны Мәмдәл волосте Зур Кавал авылы кешесе Шакир Зариповка сүз бирде:

— Исәнмесез, каваллар!..

Берничә генә сүз әйтә алды Шакир абый. Әмма безгә шул җитте. Шуннан соң радиога ышанмаган кеше калмады. Хәзер радио бер кызык нәрсәгә генә түгел, чын документка әйләнде. «Радио болай дип әйтте, радио тегеләй дип әйтте...» дип, төрле вакыйгаларга дәлил итеп йөртә башладылар.

Безнең өстә культура-агарту эше генә түгел, хуҗалык кампаниясен дә волком безгә тапшыра. Икмәк әзерләүдә катнашабыз, заем таратабыз, үзара ярдәмләшү комитетын җитәклибез. Вәлиуллин белән Насыйбуллин — комсомоллар, ә мин — билетсыз. Алар арасында догадан мәхрүм калган әрвах сыман йөрим. Ә авылда сыйнфый көрәш бара, зур көрәш, куркыныч көрәш. Дошманның кем, кайда икәнлеген белеп булмый. Политик белемебез сай, ә партия политикасын аңларга кирәк. Крестьянга таянып эшли белегез, дип өйрәтәләр безне. Урта хәллесенә Ленин күрсәткәнчә карагыз, диләр. Аны кулактан аера белергә кирәк бит әле. Кулак алдында каушап калмыйбыз анысы, налогын да, икмәген дә суырып кына алабыз. Җитәкче органнарга алай да ярап булмый. Волость үзәгенә җыелышка чакырып алалар да аяк өсте бастырып сүгәләр. Нинди генә мыскыл сүзе ишетмибез!

Бу заманда телефон юк әле, волость үзәге кантоннан, кантон үзәге Арчага сузылган чыбык кына бар. Авыл арасында хәбәрләр кеше аркылы йөри. Бер көнне миңа волостьтан язу китергәннәр: кичке унга волбашкармага килеп җитәргә.

Килеп җиттем. Түрдә ике-өч начальник утыра. Артта ят бер кеше — кантон вәкиле басып тора. Залдагылар күп түгел, авыл советларыннан биш-алты кеше, шулкадәр үк укытучылар. Беренче итеп рәислек итүче миңа дәште. Исем-фамилия белән дә, «иптәш» дип тә түгел:

— Кавал!

Сикереп торып бастым. Үземне суд алдындагы җинаятьче итеп сизәм.

— Соң, кулаклар рәхмәт укыдымы үзеңә? — ди рәис дорфа гына.

Ачуым бугазыма утырды, хурландым. Шулай да сабырлыгымны җыеп:

— Берни аңламыйм,— дия алдым.

Теге урыныннан ук сикереп торды, кызып-кызып сүгәргә тотынды:

— Аңламассың шул, ачык авыз булып, сыйнфый сизгерлегеңне югалткач! — диде.

«Кантон вәкиле гайрәтлелегемне күрсен әле» дигәндәй, акырып-кычкырып тирги, политик сүзләрне урынлы-урынсыз сибә. Чыннан да, кантон вәкиле аңа «молодец» дигән төсле карап алды.

— Бу егет кайсы авыл советы рәисе? — дип сорады.

— Рәис түгел ул, укытучы,— диде теге.

Вәкил артка таба чайкалып китте:

— Укытучы?! — дип гаҗәпләнеп сорады.— Укытучының эше бик җитди һәм җаваплы — укыту һәм коммунистик тәрбия бирү. Ә сез икмәк әзерләү эшен аңа тапшырып, аны төп хезмәтеннән аерасыз. Волость үзәгендә — үзегез, авылларда авыл советы кул кушырып утырасыз...— дип башлап китеп, тетмәсен тетте рәиснең.

* * *

**1927** елга аяк бастык. Берзаман телгә Солтангалиев исеме килеп керде. Кем ул, кайдан килеп чыккан, нинди гаебе бар? Без моңа җавап бирә белмибез. Сораганнарга: «Начар кеше ул!» — дип кенә әйтә алабыз.

Солтангалиевчелеккә каршы җыелыш арты җыелыш булып тора, аның хакында газеталарда язылa, әмма нинди гаебе барлыгын барыбер аңлый алмыйбыз. Аңа каршы җыелышларда чыгыш ясамасаң, сине дә солтангалиевчелектә гаеплиләр. Кулга алулар да ишетелә.

...Җыелышларда президиумнарда утыручыларны күрә идем дә, болай дип уйлый идем: «Бу кешеләр үзләренең шәхси тормышлары хакында бер дә кайгыртмыйлар, җәмәгать эше буенча туктаусыз йөреп торалар. Керсез, саф кешеләр, партия эшенә, власть

эшенә бөтен гомерләрен багышлаганнар». Соклана идем шуларга, шуңа күрә үз тормышымны уйларга ояла идем...

Бу җәйдә Кинешма шәһәренә — әнинең энесе Галим абыйларга кунакка бардым. Аның белән бер заводта теге чакта мине комсомолдан алып очыруда ярдәм иткән Солтан Игъламов та эшли иде. Алар хәзер икесе дә — эшче сыйныфы вәкилләре. Хезмәтләре, бәхәсләшмим, авырдыр. Анысы миңа күренми. Минем өчен кызыклысы шул: өйгә кайткач, гел үз тормышларын гына кайгыртталар — ашау-эчүне планлаштыралар. Тәмле дә булсын, арзанга да төшсен, кайбер нәрсә бушка да эләксен, ягулык дәүләт исәбенә булсын, өс-баш киемен дә арзангарак эләктерергә кирәк... Өйдә завод хәле, гомумән, иҗтимагый тормыш турында сөйләшү бөтенләй юк. Хәлбуки абый да, Солтан да — коммунистлар.

Менә шундый капма-каршы күренешләр, аларны аңларга тырышу белән бәргәләнеп көннәрем уза.

Энергиям ташып тора. Педагогик эшкә вакытны да, көчне дә күбрәк куям. Шулай булырга тиешлектән генә түгел, омтылышым, мәхәббәтем шуны таләп итә. Җәмгыять системабызны өйрәнәм. Партия, совет, комсомол, пионер нәрсә — үзем өйрәнеп, балаларга өйрәтәм. Үз ягыбызның тарихын өйрәнү эшенә дә керештем. Дәрестән тыш вакытларда укучыларыма җырлар өйрәтәм. Халык көйләренә сүзләрен үзем язам — иске халык җырларын өйрәтүне «дәү абыйлар» яратмый, тыялар.

**1929** елның кышына кергәч, эшләр тагын да җитдиләнеп китте: колхоз оештыра башладык. Авылда иң төп ярдәмчеләребез — Габит Вәлие белән Нәмәтә Яруллασы иде. Әмма алар да колхозны үзләренчә аңлый. «Аның төп максаты — крестьянның хезмәтен җиңеләйтү, тормышын яхшырту һәм баету булырга тиеш»,— диләр. Берничә генә хуҗалыкны ияртеп, авылдан чыгып китәргә дә таба кебек тип-тигез Бәйрәт басуына күчеп утырырга хыялланалар. Ягъни эксплуатациясез генә яңача кулак булалар. Бу хакта әйткәч, Вәли абзый кеткелдәп көлде:

— Ник, кеше көченнән файдаланмагач ярый ул,— диде.

— Юк, Вәли абый,— мин әйтәм,— элек дәүләт интересын карарга кирәк,— дим.— Партия өйрәткәнчә, илне — азык белән, промышленностьны чимал белән тәэмин итү өчен товарлыклы эре социалистик авыл хуҗалыгы производствосы кирәклеген, вак крестьян хуҗалыгының илне тәэмин итә алмаячагын аңлатам. Колхоз системасы аша крестьянның үз тормышы да хәл ителәчәк. Хезмәт җиңеләячәк, чөнки заман тудырган зур техниканы колхоз хуҗалыгының ызансыз кырларына гына кертеп була.

Эш авыр барды. Менә колхозчы булып эшләрлек, үз кул көче белән әйбәт кенә дөнья көтә белгән агайларны өстерәп тә колхозга кертеп булмый. Әйе, агайның иманы булып җанына һәм канына сеңгән хосусый милекчелек, шәхси тормыш аны тотып тора. Шуннан аерылса, аңа дөнья җимерелер, шул дәһшәт эчендә имансыз калыр төсле. Ә без теләмәгәннәре, колхозга алуны сорап, үзләре гариза күтәреп киләләр, йөдәтеп бетерәләр.

Без, актив, ике көннең берендә волкомга чакырылабыз; төн йокысы юк: теләсә нәрсә эшләргә, теләсә ничек аңлатырга, әмма колхозны булдырырга! Аңлаттык. «Галиябану»дагы Бәдри әйтмешли, «аңлаткач, аңладылар». Кайберсен шүрләттек, куркыттык, янадык, кайберсен, үзе теләмәсә дә, колхоз әгъзасы иттек. Колхоз оешты. Әмма... төзелеп бетеп, бер-ике көн торгач та таралды, пыр тузды. Безнең хезмәт тә җилгә очты.

Ат, арба-чана, дирбия, сабан-тырма кебекләрнең исәбен алырга билгеләнгән Кырый Газизулласы сыер-сарыкларны һәм кош-кортларны да санап йөргән. Шуның өстәвенә кемнеңдер авызыннан «алтмыш метрлы юрган» сүзе дә таралган. Шул хәлләрдән соң халык курыккан, котырган. Авыл советына груһ-груһ булып киләләр, чыдап кына тор!

— Гаризамны кире бирегез!

— Калхуз булыр хәлем юк!

— Бирегез гаризамны!

Авыл советы секретаре Каюм абый Әкбирев барлык гариза кәгазьләрен учлап алып тәрәзәдән томырды.

Авылда партия оешмасы юк. Булырга тиеш дигән төшенчә дә юк.



Партиялеме син, партиясезме — иҗтимагый җаваплы эш авылдагы укытучыларның берсе өстенә төшә. Олы Кавалда мин инде ул. Авыл советы ул миннән кала гына. Һәр җирдә шулай.

Менә волисполком бинасында чираттагы җыелыш. Икенче кеше итеп мине бастырдылар.

— Колхозны ник тараттың?!

Ниләр генә ишетмәдем. Соңгы сүз итеп шуны әйттеләр:

— Йоклама. Кайт та колхозыңны яңадан оештыр.

Йокламадым. Эшне өр-яңадан башлап җибәрдем.

**1930** елның **5** февралендә коллективлаштыруның темпы хакында Үзәк Комитетның карары булды. Урыннарда шул карарның үтәлешен тикшерү башланды. Мин, волком исеменнән, ике колхозчыны ияртеп чыгып, тау башы Әхмәтҗанны раскулачивать иттем: бер бозау, бер дини китап табып чыктым. Димәк, кулак Үзәк Комитет карарын бездән алда белгән, Әхмәтҗан йортында сәнәк белән айкасаң да, башка бернәрсә дә эләкмәячәк. Хатыны, фонарь яндырып, идән астында бәрәңге чүпли, бармак башы хәтле ул бәрәңге идән астының төбенә генә җәелгән. Әхмәтҗан үзе тунын кигән дә түр башында утыра, бүрәнә күк бармаклары белән өстәл өстен тыпырдата: әнә, тапсагыз, алыгыз, янәсе. Ә малны бик оста яшергән. Кыскасы, Әхмәтҗан кебекләргә карарны алдан белеп торган коммунистлар үзләре үк ярдәм иткәннәр, башкача булуы мөмкин түгел.

Авылдагы ике мәчетнең берсен мәктәп иткән идек. Вакытлар тагын үзгәреп китте, чигенү килде. 2 мартта Сталинның «Уңышлардан баш әйләнү» исемле мәкаләсе басылып чыкты. Почта, гадәттә, туры үземә килә; әле ул миңа газеталарны китереп җиткермәгән иде, авылның ата контры — Сүтә Сабиры капкама шакыды. Кулында — газета, шаккатып калдым. Сабир:

— Нәгыйм әфәнде, безгә мәктәп ачкычын бир әле, без, мөселманнар, иптәшебез Сталинның сүзләрен укыйбыз,— дип вәземләде. Миндә бер төрле информация юк иде, ни дип тә җавап бирә алмадым. Өстәвенә капка астындагы ачыклыктан ун пардан артык аяк күренә. Волость белән сөйләшеп алырга телефон да юк.

Ачкычны Сабир кулына бирмичә, үзем алар белән бергә мәктәпкә киттем. Хурланам, үземне әсир төшкән солдат хәлендә сизәм. Мәктәпне ачып керттем. Тегеләр, үтерелгән бәрән янына җыелган бүре өере шикелле тупланып, миңа карап торалар.

— Мәкаләне бозып укымагыз, провокация таралырлык булмасын,— дигән булдым да кайтып киттем. Өйдә үземә дә газета китергәннәр. Мәкаләне бөртекләп укып чыктым. Нишләргә дә белмим, киңәшләшер кешем юк. Ат җигеп, волкомга киттем. Әмма анда да халыкны җыеп әлеге атаклы мәкаләне аңлату эшен минем үземә йөкләделәр.

Эшләр кабат кирегә сүтелә башлады. Мәчетнең урта ишегендә ай итеп кисеп ябыштырылган клеенка кисәге бар иде, аннан укытучы Рәүф абый чебен үтерергә чапалак ясаган икән. Мәчет куштаннары шуны таптыра башлады.

Мәннәф Мәрдәнов дигән егет авылда Осавиахим оешмасын җитәкли иде. Оешма әгъзаларын винтовкадан атарга өйрәткән. Атып, мәчет манарасының гөмбәзен тишкәләгәннәр. Мәннәф хәзер картлар каршында суд хөкеме көткән җинаятьче кебек басып тора. Тегеләр манарага яңа гөмбәз куюны таләп итәләр. Бәхеткә, оешма әгъзаларының икесе әлеге мәчет куштаннарының малайлары булып чыкты, бу тавыш озакка бармады.

«Уңышлардан баш әйләнү» колхозны дер селкетеп алды. Крестьяннарның бер өлеше тагын колхоздан күтәренеп чыгып китте. Без дә көчләми башладык.

Шундый «бураннар»ны үткәреп, язга килеп чыкканда, эшләр кабат җайга салына башлады. Халыкның байтагы кабат колхозга керде. Мәчет тә җиңел генә яңадан безнең кулга күчте. Әмма шул көннәрдә авылда бер гаҗәп хәбәр таралды:

— Һәр таңда манарада фәрештәләр азан әйтә!

Бу ни хәл? Эзләнәм, койрыгы пешкән мәче сыман чабам. Мәчетне (мәктәпне) ике йозак белән биклим, «фәрештәләр» керергә юл юк. Ә азанны һаман ишетәләр. Мәктәп эчендә кунып та карадым. Соңыннан гына белдем: үземнең фатир хуҗасы Сәфәр карт, чорма тәрәзәсеннән башын тыгып, азан кычкыра, имеш!

* * *

Мин үземне бик зур кеше итеп сизәм хәзер. Ник, шулай булмый ни! Ел саен җәйге каникулда Арчада укытучылар курсында укыдым. Быел менә җидееллык белемемә барлыкка документ алып кайттым. Читтән торып педагогия техникумына укырга кердем. Хәйран барам. Яхшы беләм: бәхет ул мине үзе эзләп йөрми, мин аны үзем эзләп табарга тиешмен. Әмма бәхет эзләү алымын миңа өйрәтүче юк. Үземне үзем белә башлаганнан бирле үз тәрбиямдә яшим. Киңәш бирүчем дә, тормышның хәтәр сукмакларыннан җитәкләүчем дә юк. Хаятым диңгезендә алга таба да йөздем, артка таба да киткәләдем. Бата башлаганда үземне үзем коткарып та калдым. Тормыш сорауларын кайсын дөрес, кайсын ялгыш-йолгыш чиштем. Дөресләре белән гомер итә тордым, ялгышлары үкенечкә кала бирде...

* * *

**1931** ел минем өчен истәлекле вакыйгаларга бай булды. Гаилә кордым, романтика эзләп, шәһәргә чыгып киттек. Яшь йөрәк исәрлеге, дөнья җитми! Эш табылды, «Кызыл Татарстан» газетасына әдәби хезмәткәр булып кердем. Редактор Исхак абый Еникеев гайрәтле карашы белән миңа күз ташлады:

— Укытучы, дисең? Алайса, грамотный инде син, яхшы язасың?

— Булдырам! — дип ярып әйттем.

— Авыл хуҗалыгы бүлегендә эшләрсең,— дип, Исхак абый ризалыгын бирде.— Хезмәт хакың алты айга кадәр **60** сум булыр, шуннан соң күрербез. (**60** сумга бер генә ай эшләдем. Шуннан соң 120 сум ала башладым, бераз каләм хакы да кирә иде.)

Редакция булгач, төрле кеше керә-чыга йөри. Менә атаклы шагыйрь булып үсеп җиткән Һади Такташ җилфердәп килеп керә, җаваплы секретарь Әхмәт Исхакның өстәл башындагы урындыгына килеп утыра, эшенә комачаулый. Кәрим Тинчурин да, керсә, шул урындыкка килеп утыра. Ул аз сүзле, безнең эшләгәнне тыныч кына күзәтеп утыра. Астагы каттан, чыр-

кылдап, «Азат хатын» журналы редакторы Гөлчирә апа Гафурова менә. Татиздат управляющие Самат абый Шәрәфетдинов та бездә еш була. Такташтан зарлангалый. Дон Кихот итеп ясалган мундштугына папирос кыстыра да үпкәләгән бала тавышы белән сөйли:

— Такташтан качып кердем,— ди.— Язылмаган, кайчак язылачагы да билгеле булмаган шигырьләренә акча сорый. Үзәккә үтте инде...

Кави Нәҗми һәрчак хәрби мундирдан йөри. Тыйнак, гади кеше. Очраганда, таныса-танымаса да, сәламләшмичә китми.

Түгелеп-чәчелеп, зур портфелен тотып, Фатих Сәйфи-Казанлы килгәли.

Бу вакытта газетаның игъланнар бүлегендә Галиәсгар абзый Камал эшли иде. Драматурглык шөһрәте беткән иде инде, үзен бик кимсетәләр иде. Эчкәли иде, шул кимчелеген сылтау итеп, гел кага килделәр. Бигрәк тә Фатих Сәйфи-Казанлыдан зарланганы исемдә. Ялга чыгарганнан соң, кабат эшкә алмадылар. Әмма аның урынында зур булмаган хезмәт хакына эшләрлек кеше юк. Мине куйдылар. Игъланнар күп килә, барысы да рус телендә, ятышлы итеп тәрҗемә итәргә кирәк. Өстәвенә наборщиклар белән дә талашырга туры килә.

...Әмма күпме генә тырышсам-тырмашсам да, эшемә инде күнегеп, яратып өлгерсәм дә, шәһәрдә озак мантый алмадым. Мин үзем генә түгел, хатыным, нәни кызым бар, аларны туендырырлык акча эшли алмыйм. Һәр җирдә коточкыч кыйммәтчелек, өстәвенә төпле генә торыр җиребез дә юк, тегендә күченеп, монда куылып йөрибез. Шул рәвешле, тормыш безне кабат авылга куып кайтарды. Бу юлы Дөбъязга кайттык, ШКМга укытучылар кирәк икән. Мин нинди дә булса фәннең белгече түгел бит, ни тәкъдим итсәләр, шуңа риза идем. Хатыныма математика эләкте, ул аны әйбәт белә. Миңа тарихтан башка предмет калмады. Тырышсам, укысам, булдырырмын, дип уйладым. Әмма завуч Тәкый ага Бәдигъ авыр мәсьәләне чишә алмый тилмергән кебек:

— М-м... да,— дип куйды.

Тарих — «политический предмет» икән, ә мин би-

летсыз гына большевик, беспартийный. Олы Кавалда минем белән бергә эшләгән Лотфи Насыйбуллин — комсомол, шулай булгач, тарихчы булып ул калды. Миңа аннан химия белән биологияне күчерделәр. Лотфи тарихның «т»сын да белмәгән кебек, мин дә химиянең «х»сын, биологиянең «б»сын белмим. Фәннәрнең үзләрен белмәгәч, методикасын каян белим? Ничек укытыйм? Моны кычкырып әйтмәдем, билгеле, үземне геройларча тоттым. Ары кагылдым, бире сугылдым, химия-биология буенча нинди китап тапсам, бәясе дип тормадым, барын да җыйдым. Ирле-хатынлы төн йокламыйча укыдык, өйрәндек, хезмәт күрсәтергә тешебез-тырнагыбыз белән ябыштык.

Мәктәптә җыелышларның башка төрле исемнәре юк, ике көннең берендә «педсовет» дип җыелабыз. Төн буе утырабыз. Мөдир Хәйрулла Вәлиуллин (теге вакытта Кавалда избач булып эшли иде) берүзе сөйли: «Әгәр дә если...» дип башлап китә дә, заводной механизм төсле сыптырып кына тора. Сөйләве һәр җыелышта бер үк эчтәлекле: укытучыларны сүгү. Һәр укытучыны берәмләп сүгеп чыга, куркыта, яный. Чөнки ул бик шикләнүчән, аның карашынча, мондагы укытучылар партиягә һәм хөкүмәткә дошман күз белән карыйлар, корткычлык эшләргә генә торалар. Аныңча, партиясез булу — соң дәрәҗәдә хурлык, андыйлар коточкыч хәтәр кеше булып исәпләнәләр. Вәлиуллин янына партияле кеше килеп, икесе бер бүлмәдә сөйләшеп утырганда, партиясез кеше килеп керсә: «Мөмкин түгел, чыгып тор»,— дип борып чыгаралар.

Мин исә партиясез, әмма чын күңелдән җәмгыять өчен эшлим, социализм булачагына тулы иман белән ышанып яшим.

* * *

Тырыштым. Хәзер мине районда таныйлар. Мин — белемле (техникум тәмамлап кайттым бит), нык, ышанычлы кеше. Шулай саналам. Әмма мин партиясез, шуңа күрә үземне кимчелекле кеше итеп сизәм...

**1936** елда эш шартлары бик авыр булды. Без инде туган авылым Мәмдәлдә яши идек, ике бала белән мәк-

тәп фатирында торабыз. Ул елны начальникларның рядовойларны сүгүе, янавы, куркытуы, юк өчен гаепләве модага керде. Рядовойлар арасында куштаннары да, тәлинкә ялаучылары да бар. Кечкенә генә ялгыш сүз ычкындырсаң, берсе эләктереп ала, икенчесе үзгәртә, өченчесе югарыга ирештерә. «Иптәш Сталин», «остазыбыз Сталин», «Иосиф Виссарионович» сүзләре диндар кешенең тәсбихына әйләнде, «сөбханалла»дан артыграк кабатлана иде.

Шундый заманның бер төнендә, тәвәккәлләп, хатынымның этисенең хәлен белергә барып кайттык. Ул Орнаш Башының (хәзерге Әтнә районы) элекке мулласы, «мулла белән мөнәсәбәткә керәсез» дип гаепләнүең дә бар. Шуңа күрә без моны бик тә яшеренеп эшләргә мәҗбүр булдык.

* * *

**1941** елның 22 июне. Сугыш!!!

Сәгать суккан саен, минут үткән саен, берсеннән-берсе күңелсез хәбәрләр килеп тора.

Фашист илбасарлар безнең бөек Ватаныбызга бик тирән кереп өлгергәннәр икән. Дәһшәт белән киләләр, ди. Илебезне пычраталар. Кайда безнең сугышка каршы әзерлегебез, бик гайрәтләндек, бик мактандык лабаса? Юлбашчыбыз Сталин ни әйтә? Аны, мөгаен, алдаганнардыр. Ә ник алдансын, даһи бит ул?!

Көн саен хәрби комиссариаттан чакыру килә. Авылның типсә тимер өзәрлек, басса бакыр изәрлек егетләре груһ-груһ чыгып китәләр. Күп тә үтмәде, үлгән хәбәрләр дә килә башлады. Кайтучылар да булды: кайсы култык таяклы, кайсы кулын марля белән муенына аскан, күзен бәйләгән...

Менә китәм, менә китәм, дип йөреп, бер эштә дә күңел юк. Инде җәй үтеп бара, әле һаман военкомат мине чакыртмый. Минем бер төрле дә сугыш һөнәрем юк, шуңадырмы, югары белемле укытучылар исемлегендә торгангамы икән...

Куркыныч дәһшәт, хәсрәт көннән-көн арта бара. Тылда ятуыма хурланам, үземне җинаятьче итеп хис итәм. Куркак, җебегән бәндәнең качып ятканы кебек бит. Сугышка үзем теләп китәргә әзерләнәм, үзем вин-

товка рәтен дә белмим. Шуның өчен бик кайнарланып винтовканы өйрәнә башладым: сүтү тәртибен, частьларның исемнәрен, җыю, кору, ату...

Фронт файдасына ике данә мех куртка тапшырдым. Ләкин соңыннан белдем: җыелган әйберләрнең яртысы да авылдан чыгып китмәгән, коммунист түрәләр бүлешеп алып бетергәннәр!..

Мин — партиясез гади гражданин. Шуңа күрә коммунистлардан чын күңелдән оялам. Әмма алар миннән бик күпкә түбәннәр, вак җанлылар, оятсызлар икән ләбаса! Чын йөзләрен партбилет һәм коммунист дигән исем генә каплап тора икән. Сугыш башланыр алдыннан гына менә берәү офицер киеменнән авылда кукыраеп йөрде. Сугыш башланган көнне үк мундирын салып ыргытты. Штатски киемгә күчте, аксаклап, таякка таянып йөри башлады. Коммунист буларак райкомны ышандырды, врачын да җайлады, сугышка яраксыз кеше булып калды. Бөтен сугыш дәверенә райком аны авыл советы рәисе итеп куйды.

...Военкоматка сугышка алуларын сорап баргач:

— Тылда эшләү кыенлыгыннан качасың,— дигән мөһер суктылар.— Вакыты җиткәч, чакыртып алырлар,— диделәр.

Алай гына да түгел, фронтка киткән Петров урынына мәктәп директоры итеп билгеләндем. Бу минем өчен дәрәҗә, зурлык түгел, хурлык. Җәһәннәм газабына тагын берсе өстәлде. Укучыларда уку дәрте, укытучыларда укытуга ихлас бөтенләй юк. Әмма эшне тартырга кирәк. Чумдым эшкә, үземне-үзем аямыйм. Мәктәпне кышка әзерләргә, укытучыларны утын белән тәэмин итәргә кирәк. Мораль яктан да, физик яктан да әйтеп бетергесез кыен. Чыдар хәлем калмады, китәргә дигән ныклы карарга килдем. Монда да фронт, монда да мин кирәк, әмма мондагы газап патриотлыкка саналмый.

Карарымны тормышка ашырам дигәндә, 1942 елның мартында бронемны военкомат үзе сорап алды.

Авыр... Яшәгән, гомер иткән җирләр кала... кадерле, газиз гаиләм кала. Вакытлыча гына дип әйтеп булмый бит.

Шулай икән ул дөнья дигәнең, үлем еракта ук күренеп килә башласа, башта бик куркыта икән. Килеп

җитәрәк курку да акрынлап басыла икән. Чөнки ышанган инде — барыбер бетәбез.

Товар поездында Казаннан чыгып киттек. Менә шунда инде яңа тормыш башланды. Вагон уртасында тимер мич яна. Ятып түгел, ичмаса, сөялеп йоклап барырга да җай юк. Кемдер мине кызганырга тиеш шикелле, кемгәдер иркәләнәсе килә, ләкин берәү дә юк: әнием дә, хатыным да, балаларым да... Бу минутта алар нишлиләр икән? Без артык тыйнак яшәдек, запас юк. Кышны ничек чыгарлар, ә язгы су вакыты өчен балаларның аяк киеме бар идеме икән? Җылылар башланганчы утын җитәр микән?

15 мартта Арзамаска барып җиттек. Станциядән шәһәргә таба берничә чакрым тәпиләргә туры килде. Ачык кыр. Көнбатыштан, гайрәтләнеп-гайрәтләнеп, март җиле исә, кыр өстеннән җәяүле буран йөгерә, шактый югары күтәрелеп бара торган кояш, болыт артыннан чыгып, бер елмая да кереп кача. Яз килә, янәсе. Хәсрәтле яз. Күңел аны да килеп җитә алмас кебек сизә, кояшның елмаюы да авыру кешенең үләр алдыннан булган бер җиңеләюе шикелле генә булып кала.

Менә Арзамас. Шәһәрчек. Башта кызган аяк белән шәһәрне бер айкап чыктык. Иске заманнан калган чиркәүләр, монастырьлар, соборлар белән тулган икән.

Менә ишегенә Александр Пушкин портреты куелган ике катлы таш бина. Мәктәп икән. Тукта, бу ни хәл? Рус шәһәрендәге рус мәктәбе эченнән татар моңы ишетелә! Коридорга уздык, чытыр-чытыр китереп пыяла ватыклары өстеннән үттек. Әнә химия кабинеты, ул туздырып ташланган, идәндә — пробирка, көпшә ватыклары. Шәһәр дошман оккупациясендә булмаган лабаса, бу ник болай? Кем вәхшилеге бу? Минем кабинетым да шундый хәлдә микән? Аһ!..

Бүлмәләрдә идән калын пычрак катламы белән капланган. Димәк, мәктәпнең төп хуҗалары биредә күптән юк инде, көзге пычрактан ук ниндидер затсызлар хуҗа булып алган.

Тавыш килгән якка барып, җырлаучыларны эзләп таптык. Үзебезнең Татарстан егетләре, алар да безнең кебек килгәннәр. Шул пычрак идәндә җырлый-җырлый ауныйлар. Күбесе — укытучылар. Шатландык,

кардәшләребезне тапкандай булдык. Алар белән бергә пычракта аунарга уңайсызлануым өчен үземнән үзем көлдем.

— Әрсезлектә — эт, шакшылыкта — дуңгыз. Солдат әнә шул инде,— диде берсе.

Әйе, дуңгызга әверелеп барабыз бугай.

Күңелсез. Һәркемнең карашы моңсу, өметсез. Җиңүен җиңәрбез, анысында шик юк, өч йөз елдан артык тиранлык иткән Романовлар сәләмәсен себереп түккән халык власте бездә!.. Әмма яшисе килә, тынычлык сагындыра. Ярар, хәерле булсын, изге юлда йөрибез. Ватан өчен үләбез, шуның белән горурланабыз. Сугыш белеме алып, үлгәнче оста итеп сугышып та карыйсы килә. Бәлки... сугыш туктар дип тә өметләнәбез.

Безнең урын «пулеметно-минометное училище» дип атала, без шул юнәлешнең офицерлары, иң кимендә лейтенант булып чыгарга тиешбез.

Минем монда иң беренче шатлыгым шул: винтовканы бик яхшы үзләштердем. Бар хурланганым шуны белмәү иде. Гомумән, минем өчен теория бик җайлы. Әмма строевой фән һәм тактик занятиеләрне авыр кичерәм. Өстемдәге киемем җылы, хәрәкәтләнгәндә тирлим, аннары шул килеш март кары өстендә сәгатьләр буе ятарга туры килә. Организм алҗый, самсырый, су сорый. Чәй дигән нәрсә юк, кайнаган суның ни икәнен белмибез, хәтта салкынына да тилмерәбез. Су колонкасының үз эшләү вакыты бар, шуны туры китереп, кисмәккә салкын су хәзерләп куя башладык.

Тәнем кызыша, төннәрен саташып чыга башладым. Актык көчем белән аяк өстендә йөрим. Авыруым көчәйгәннән-көчәя бара. Взводташларым хәлемне аңлыйлар, стройдан качырып, мине санчастька җибәрделәр. Икенче каттагы салкын бүлмәгә менгереп салдылар. Бөтен дәвалаулары — кереп, температураны үлчәп чыгып китү.

— Шушында ял итеп яту — үзе дәва инде ул,— ди врач.

— Мин арымадым,— дим.— Занятиеләрем кала, миңа терелергә кирәк.

Бу — кылану түгел, ихластан әйтелгән сүзләр. Пла-

ным чуалды, укырга, офицер булырга иде бит исәп. Үлсәң, күпләр белән бергә бетәсең, исән калсаң, Ватанга керткән өлешең белән горурланасың. Миңа исә болай хастаханәдә ятып, эзсез югалырга туры килер микәнни?!

Хәлем авырайганнан-авырая. Күкрәк чәнчи, сулап булмый, саташам, йоклап китә алмыйм, күземә әллә ниләр күренә. Ишек ачылды. Кап-кара шәлгә төренгән зур гәүдәле бер карчык килеп керде. Күзләрен миңа текәп, караватым янына килде, кулымнан тотып тарта башлады. Мин:

— Таня! — дип кычкырып җибәрдем, аңыма килдем, сестра Таня да яныма килеп, юатып китте. Бик әйбәт кыз ул, авыруларны чын ихластан тәрбияли.

Беркөнне мине, дубырдап бара торган ләҗәнкә арбага утыртып, рентген кабинетына җибәрделәр. Урамда яз, кар эри, чылтырап сулар ага, җилпенепҗилпенеп сыерчык сайрый, тургай җырлый-җырлый күккә күтәрелә. Яз матур, Арзамас урамы гына ямьсез, пычрак, урам уртасындагы тирестә сикерә-сикерә карга оча...

Рентгеннан соң авыруым ачыкланды: уң як үпкәмдә абсцесс икән. Врачның әйтүенә караганда, мине монда гына дәвалый алмыйлар икән, каядыр башка җиргә озатырга тиешләр.

Алатырьга икән. Товар поездының салам түшәлгән салкын вагонында өч тәүлек теркелдәргә туры килде. Ул ватык үпкәм ни күргәндер. Сызлануымны һәм ютәлемне җиңә алсам, уйларым үткәннәремә тоташа: нинди хыяллар белән яши идем бит, һәм хәзер кем булып калдым? Кем булыйм — имгәк. Гаиләм өчен дә, Ватаным өчен дә — имгәк!

Хәлем авырайганнан-авырая бара. Үпкәмнән кан килә, ашап булмый, гәүдә хәрәкәтем белән идарә итә алмыйм, авырту һәм температура белән җәфаланам. Мондый хәлдә терелүемә өметләнү күктән йолдыз чүпләргә сузылу белән бер булыр иде. Күзем ачык, ә дөньяга саташып карыйм, уйларым буталчык, өметсезлек зур, апатия көчле.

Җылы көннәр башланды. Менә саташудан айнып карап ятам. Май таңы ата. Тәрәзәм каршындагы нарат болыт-болыт сап-сары серкәсен очыра. Палата тә-

рәзәсе башында күгәрчен гөрли. Менә кояшның тәүге нурлары нарат агачлары арасыннан кысылып кына бүлмәгә төшә...

Ә беркөнне палатага госпиталь начальнигы керде, мине карады һәм озакламый «комиссовать» итәчәкләрен әйтте.

И адәм угылы, яшәү ул башыңа теләсә нинди хәлләр килергә мөмкин генә түгел, килергә тиеш дигән сүз. Бәхетле яки бәхетсез булсаң да, табигатьнең теге яки бу продукциясеннән (мәхәббәттән, таланттан, матурлыктан, көчлелектән...) өлешле яки өлешсез булсаң да... бернигә дә гаҗәпләнмә. Яисә шатланып күккә сикермә, хәсрәтләнеп аһ-ваһ итмә, уңаен да, тискәресен дә тыныч күңел белән кабул ит! Чөнки син — Кеше!

6 июнь көнне «авыруы дәвалап булмый торган» дигән документ тотып, өемә кайтып егылдым. Сугыш башлангач, мин болай булырмын дип, күз алдыма китерделммени? Инде менә башкалар фронтта сугышканда, батырларча һәлак булганда, син өйдә үлем көтеп ят, имеш...

Тормышны алып бару хатыным өстенә төште. Балаларны карый, колхоз эшенә йөри, укыта, тамак туйдырырга җай эзли. Аның хәле чиктән тыш авыр, әмма ярдәм итәрдәй көчем юк. Милкебездән кеше алырдайларны сатабыз. Ә алучы бар!

Хатыным үзен аямыйча мине дәвалый. Сыерыбыз булмаса да, сөт табып, катык ясый, шәһәргә илтеп сата, «спекуляция» ясый, азык таба. Дуңгыз мае алып кайтып эчерә. Шулай өметләнеп йөргәндә, моңа кадәр күренмәгәнчә озак һәм каты йөткердем. Үпкәмнән көчле кан китте, чишмәдәй шаулап акты. Хатын больницага йөгерде. Врачлар Романов белән Ошанина да мине күргәч каушап калдылар.

Бу юлы да исән калуыма хатыныма бурычлымын. Җир йөзендә тиңе булмаган кыйммәтле зат ул!

Шушы хәлдән бер айдан да азрак вакыт узган иде — хәрби комиссариатка чакырдылар. Биредә язып утыручыларның чиге юк — таза, нык, матур ирләр. Бу эшкә хатын-кыз яисә гарип-гораба ярамый микәнни?

Миңа: «Суслонгер»,— диделәр.

Суелырга хәзерләнгән малларны бер урынга туплаган шикелле җыеп, Суслонгер командасын оештырдылар.

* * *

Мин унтугыз ел буена совет укытучысы булып хезмәт иттем, унтугыз ел буена һәрьяклап агитация алып бардым. Ә менә монда, Суслонгер лагеренда, үзем сөйләгәннәрнең киресен күрдем. Без — совет солдатлары, безне монда каршы алучылар да — совет командирлары, шулай булгач, без һәммәбез дә бер гаилә кешеләредәй булырга тиеш. Тик командирлар безне дошманнарча каршы алдылар, безгә качып йөргәндә тотылган дезертирлар итеп карыйлар. Җылы сүз, якты караш, иптәшләрчә мөнәсәбәт юк.

— Быстро приготовим вас пулеметчиками и отправим прямо на фронт! — Әнә шулай аерым бер тәм белән куркытып сөйләргә яраталар. Без әле дөнья күрмәгән, янәсе, куркабыз. Болар исә «дошманнарыннан» үч ала, алар сугышта чакта без тылда ятканбыз!

Миңа нәрсә, өйрәнермен пулеметын да, сугышырмын. Мондый куркытулар миңа энә очы кадәр дә тәэсир итми. Мин генә түгел, күпләр кырылды. Өйгә исәнсау кайтырмын дип өмет тә итеп килмәдем, балаларымны соңгы тапкыр дип сөеп, бәхилләшеп килдем. Ватаным өчен сугышып үләргә дип килдем.

Без көне буе занятиедә. Миңа хәлсез килеш егерме сигез килолы пулемет «тело»сын күтәреп йөрергә туры килә. Кичен урманга утынга барабыз. Ашханәдә бәрәңге боламыгыннан башка нәрсә юк, гомумән, анда бару — җан газабы. Күршедә генә офицерлар ашханәсе, аннан тәмле ашларның хуш исе борын түрен кытыклый, ашказанын котырта. Офицерларның солдатларга мөнәсәбәте әшәкеләнгәннән-әшәкеләнә бара. Әйтерсең бу хәрби әзерлек урыны түгел, ә ниндидер зур җинаять эше белән тотылганнар өчен җәзалау лагере. Акырып кычкыру, сугу, мыскыллау — берсе дә калмый. Ниндидер явызлык бармы монда? Мөмкин кадәр азапларга, эштән чыгарырга, фронтка яраксыз итәргә тырышалар диярсең.

Менә беркөнне «преодоление препятствий»га чыктык. Мин тирән, киң чокырга кадәр барысын да үттем. Ә бу чокыр аша сикереп чыга алмыйм, хәлем җитми. Шап! — уртасына.

— Отставить! — ди офицер. Мин тагын кабатлыйм.

Тагын — шап! Тагын... Командир сүгә, акыра. Мин соңгы көчемне җыеп сикердем. Чокырның аргы стенасына килеп бәрелдем. Үпкәмнән гөрләп кан китте. Бер генә минуткадыр, аңым югалды. Күземне ачканда кан эчендә ята идем.

Гарнизон комиссиясенә баргач, өлкән яшьтәге врач күкрәгемә имән бармагы белән берничә мәртәбә төртте дә:

— Патологического ничего нет,— дип, взводыма кайтарып җибәрде.

...Ач тамак белән корбанын эләктерә алмаган карт бүре кебек, сөйрәлеп кенә казармага кайтып барам. Октябрьнең суык җиле исә, ялангач урман, үлем хәсрәтен көчәйтеп, ямьсез итеп улый, күбәләк карлар оча. Үзем ач, үлемгә барам, өйдә әниләре янында балаларым ач.

Мине ротадагы төрле халыклар арасында агитатор итеп куйдылар. Беркөнне политработникларның җыелышында да катнаштым. Миңа сүз биргәч, тыңлаучыларым турында ни сөйләгәнемне хәтерләмим, шушылай тәмамлаганымны ачык беләм:

— ... все готовы, чтобы отдать последнюю каплю крови за Родину, за Сталина! — дип, трибуна артыннан төштем. Залда — ура! Ура! Барабан бәреп алды, тынлы оркестр Салих Сәйдәшевнең маршын уйнап җибәрде.

* * *

...19 октябрьнең таңы, сәгать өч. Сигнал уйный башлады, сикерешеп тордык. Тиз генә чыгып тезелдек. Караңгы. Өстебезгә төн аша ак яфраклар шикелле җепшек кар төшеп тора. Абына-сөртенә станциягә барганда, ул кар яңгырга әверелде. Юешләнеп беттек, дуңгыз булып пычрандык. Кием юка, сыгылып, бөтен тәнгә су үтә. Туңам, калтыранам. Каны саркып торган җәрәхәтле үпкәм сыкрый, шулай да һаман исән бит әле мин. Шул юеш көйгә товар вагоннарына төялдек.

27 октябрьдә Сталинград өлкәсендәге урманга урнаштык. Берничә көннән походка чыгып киттек. Донга җитәргә илле чакрымлап бар, диделәр. Чиләкләп яң-



гыр коя башлады. Якында печәнлек бар иде. Ике взводның дүрт пулеметын коры печән белән каплadым. Гаскәр китте, без взвод командиры Свистунов һәм тагын бер пулеметчы белән шуларны саклап калдык.

Мин землянка алдына качырып кына ягылган учак яктысында пулемет тасмаларына патрон тезәм. Урман юлыннан Сталинград юнәлешенә танклар агыла... Икенче көнне безне алырга машина килде, шуңа төялешеп чыгып киттек. Бервакыт моржа улавына охшаган гүелдәү тавышлары килә башлады, алар акрынлап көчәйде. Башыбызны күтәреп карасак, безнең өстә — бер көтү немец бомбардировщиклары. Алар шаян каргалар шикелле уйнаклашалар, сиреналарын улатып, уктай түбән атылалар да, җиргә төшеп җитәм дигәндә генә кинәт күккә омтылалар, хәрәкәтләренә күз иярми. Без юлдан читтәге урман эченә ыргылып, әзерләп куелган чокырларга төшеп утырганчы, шартлата да башладылар. Тел белән әйтеп аңлаталмый торган дәһшәтле мәхшәр купты...

Донга килеп җитеп, машинаны туктатырга өлгермәдек, тагын бомбага тоту башланды. Коточкыч шартлаулар, ыңгырашулар, акырулар, ачыргаланып атлар кешнәве... Обозлар яна, машиналар яна. Мин ерак китә алмадым, бака булып җиргә яттым, башымны күтәреп караганда, алдымда тездән өзелгән итекле бер аяк басып тора иде... Бомбежка авышты, җир өстендәге кыямәт тетрәндергеч иде: яраланучылар акыра, үлем

хәлендәгеләр ыңгыраша, җирдә канлы кул-аяк кисәкләре аунап ята... Обоз атлары тырпылдаша, машина кисәкләре, арба ватыклары кайсы кая тәгәрәшеп ята, нәрсәләрдер гөрләп яна. Кайдадыр зенит тубы түпелдәгән була...

Дон өсте инде тәмам туңды, өстен юка гына кар да каплап алды. Боз өстеннән җәяүләп елганың аргы ягына чыктык. Менә әрәмәлек. Туктарга, пулеметларны көйләргә боерык булды. Без икәү — беренче һәм икенче номерлы пулеметчылар — «максим»ны куак төбенә алып килеп урнаштырдык. Ул арада дошман ягыннан «фие-фие-фие» дип, пуля да оча башлады. Иптәшем:

— Ох, руку! — дип кычкырып, артка егылып төште, берүзем калдым. Яныма патрон тартмаларын китереп ташладылар. Икенче номерлы булып яныма ятучы юк. Менә алда, җиргә сибелгән чәүкәләр төсле, кара нокталар пәйда булды, безгә таба хәрәкәт итә башладылар. Замокка лентаны да үзем тыгып, «чәүкә»ләргә озын гына очередь бирдем. Тегеләр юкка чыкты. Тагын күренә башладылар, минем икенче очередь тагын тыкылдап алды. Өченчесенә әзерләнгәндә, уң флангта миналар шартлый башлады. Арттан ачы итеп:

— Держись! — дип кычкырдылар да, аягымнан тотып артка өстерәделәр, мин «максим»ны хоботыннан эләктереп алырга өлгердем. Шулчак бая гына пулеметым белән яткан урынга мина килеп төште. Менә ничек куып йөри икән ул әҗәл!

19 ноябрь таңы ыгы-зыгы белән башланды. Һәммәбезне дә сафка тезделәр. Гомуми һөҗүм башлана торган көн икән. Майор нык тәртип таләп ителәчәген аңлатты, походта барганда, өч адым да читкә атламаска, дип кисәтте. Кулындагы ялангач наганын һавада айкый-айкый сөйләде.

— За малейшее нарушение...— дип гайрәт чәчте дә: — Үз кулым белән атып үтерәчәкмен,— дип янады. Әмма болар миңа әллә ни тәэсир итмәде: мин тәртип боза белмим, үлемнән исә гомумән курыкмыйм. Бу минем шапырынуым түгел. Фронтка килеп, аннан исән-сау кайтырмын дип тә өметләнмим, авыруым да бик җитди.

Озак бардык. Дошман туктаусыз чигенә, шуңа күрә безгә эш юк. Каршыга машиналар килә, җәяү бара торыгыз, диделәр. Төн иде инде. Бераз ял итәргә туктаган җирдә башымны күтәреп карасам, тирә-юнемдә берәү дә калмаган. Сарайлар артына кереп баручы икәүне шәйләп алдым. Үзебезнең взвод егетләре икән. Бер фатирның ишеген ялына-ялына ачтырып, винтовкаларыбызны кочаклап йокладык.

Икенче көнне юлыбызны дәвам иттек. Без үтәсе урынга туктаусыз снаряд төшә. Алларында бүре күргән сарыклар кебек аптырап торабыз да тагын алга атлыйбыз. Юлыбыз безне үргәрәк алып менеп китте, аннары сөзәкләнеп төшә башлады. Алда каплаулы машинаны күреп алдык, каршысында берничә хатынкыз һәм ир кеше май ягылган ак икмәк ашап торалар. «Майор!» — дип пышылдаштык та, куркышып туктап калдык. Димәк, безнең часть. Димәк, артта калганыбыз өчен майор безне үз куллары белән атып үтерәчәк. Иптәшләрем мине алга таба этте. Мин, уң кул бармакларымны чигәмә тиереп:

— Товарищ майор, мы...— дип әйтә генә башлаган идем, майор күн пирчәткәле кулын безгә таба селтәде:

— Брось! — диде, үзе шунда ук эш тә тапшырды: төнне ачык кырда сакта торып үткәрдек. Мин теземне чәнчеп утырып, винтовкамны аркылы сузып салдым да уйга чумдым. Менә адәм баласының язмышы. Сугышка кергәнгә әле бер ел тулмаган, ә минниләр генә күреп бетермәдем инде! Училище, коточкыч авыру, госпитальләр, комиссияләр, фронт, мин инде — гарип бер солдатмын...

Без юкка курыкканбыз: ярты юлда калуыбыз командование гаебе белән булган икән. Без юк чагында бер һөҗүм ясарга өлгергәннәр. Сугыш бик каты булган, батальонда ярты гаскәр кырылган.

Наступлениегә! Әмма ахмакларча барабыз да инде! Баштанаяк коралланган фашист-ерткычка каршы аяк өстендә көе винтовканы «наготове» тотып барабыз. Бу — хәрби эштә бер алыммы, әллә безнең командованиенең ахмаклыгымы?

Без, каршы килә торган танкны күреп алып, җиргә ятып кына өлгердек, «фи-и-и» иткән пулемет уты астында калдык. Ул арада танк алдагы хуторга кереп

китте, без — аның артыннан. Немец безне монда да ут белән каршы алды. Пуля яңгыр булып ява. Баш тыгарга урын юк. Артка чигенергә ярамый. Алга шуышабыз. Янымнан гына:

— Держи левее! — дип, взвод командиры шуышып китте. Ун секунд үтмәде, алдагы мәеткә башын куйды да... тынды... бетте.

Баш тыгарлык та чокыр заты юк, көрәгемне, винтовкамны баш очыма куеп карыйм. Әйләнә-тирәмдә пуля яңгыры җирне актара, ә мин һаман исән әле. Мин түкергән кан ак кар өстенә җәелә. Һич тә үләсе килми икән бит. Гаиләм кала, балаларым кала...

Күп югалтулар белән алдыбыздагы ике авылны алдык.

Гөрелдәгән тавышка алга, фронт ягына карадык. Бер-бер артлы тезелешеп, өч танк килә. Нәкъ минем өскә турылап киләләр. Миндә граната-фәлән юк, винтовкадан гына атам, танкның исе дә китми. Снаряд чокырына төшеп яттым. Менә килеп җитте... күп булса, ун метрлап калды... менә чокырым белән бергә сытып китә... дигәндә генә танк сул ягына кинәт борылып куйды, «кырт» итеп борынын күтәрде; көпчәк чылбыры өзелде дә, дөрләп яна башлады. Люк ачылып китеп экипаж чыга башлаганда, «Атмаска!» дигән приказ яңгыраганчы, берәү атып өлгерде. Икенче немец, чыгуга, кулын күтәрде. Аның артыннан килгән танк та шундый ук язмышка дучар булды. Өченчесе качып китәргә өлгерде. «Ур-ра!» кычкырып алга киттек.

...Үзәндә, дошман ягында калдык. Безнең тылга таба тагын бер калкулык сузылган. Шул ике калкулык култыгында, үзәндә, безнең взвод командиры Вересаев мәҗлес үткәрергә йөри. Безнең артта гына миномет ротасы ята. Вересаев кунакка шуның командирын чакырып килергә куша. Нишлисең, киттем. Калкулыкны иелгән көйгә җан-фәрман йөгереп үттем. Әмма «кунак» килә алмаячагын әйтте. Еректан әйләнеп кайттым. Вересаев чыгырыннан чыгып тузынды, чөнки шактый ук кызган иде инде. Планшетыннан кәгазь тартып чыгарды да, хәрефләрен чыпчык башы хәтле итеп записка язды. Миномет ротасы командирына мин шул записканы илтеп тапшырырга тиешмен. «Есть!»

дидем дә киттем. Бараммы соң! Исерек кушуы буенча йөрсәң монда... Юлымда иске окоп бар, шунда төшеп ятачакмын. Әмма барып җитә алмадым, көчле шартлау тавышы яңгырады. Вересаев тирәсендә ыгы-зыгы башланды. Янында гына мина төшеп ярылган, яраларын бәйлиләр иде.

2 декабрь иртәсендә — тагын ыгы-зыгы. Һөҗүмгә әзерләнергә приказ бирелде. Хәлем авыр булса да, башкалар белән бергә булырга тырышам. Өч мәртәбә ятып, өч мәртәбә тордым. Дүртенчесендә сөртенеп барып төштем, авызымнан гөрләп кан китте. Шуннан арысын белмим, аңсыз ятканмын. Күзләремне ачканда, уң кулымның терсәге һәм кулбашым үтереп сызлый иде. Җәрәхәтемне бәйләгәндә генә аңыма килдем...

# Эчтәлек

Чуфут-кале малайлары . . . . . . . . . . . . . . 3

Мәмдәлләрдә генә утлар яна . . . . . . . . . . . 41

Литературно-художественное издание

*Ляля Гимадиева*
*(Сабирова (Гимадиева) Ляля Нагимовна)*

**Мальчики Чуфут-кале**

Повести

(на татарском языке)

Редакторы *Р.Ә.Заһидуллина*
Рәссамы *А.Л.Мамаев*
Бизәлеш редакторы *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Г.М.Хәбибуллина*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 26.01.2005. Форматы $60\times90^{1}/_{16}$.
Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы. Офсет басма.
Басма табагы 5,0. Шартлы буяу-оттиск 11,0. Нәшер-хисап табагы 4,16.
Тиражы 3000 д. Заказ А-18.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.